ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 октябрь, 2017 ел № 20/8

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләрен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе, шәһәр Уставының 19, 28 маддәләре, Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге Гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезнамәне раслау хакында» 34/8 санлы Карары нигезендә,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләрен кушымтага нигезләнеп расларга.

2. Гамәлдән чыккан дип таныргa:

1) Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләрен раслау турында» 21/8 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2012 елның 19 октябрендәге 82 нче, 2013 елның 20 ноябрендәге 87 нче, 2013 елның 22 ноябрендәге 88 нче, 2013 елның 27 ноябрендәге 89 нчы саннарында бастырылган;

2) Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 26/10 санлы Карарын «Челнинские известия» гасетасының 2013 елның 06 сентябрьдәге 67 нче, 2013 елның 20 ноябрендәге 87 нче саннарында бастырылган;

3) Шәһәр Советының 2014 елның 17 апрелендәге «Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге 21/8 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында 30/9 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2014 елның 23 апрелендәге 30 нчы санында бастырылган;

4) Шәһәр Советының 2014 елның 10 июнендәге «Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге 21/8 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре

муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында 31/17 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2014 елның 23 июлендәге 53 нче санында бастырылган;

5) Шәһәр Советының 2014 елның 9 декабрендәге «Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге 21/8 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында 35/10 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2014 елның 24 декабрендәге 96 нчы санында бастырылган;

6) Шәһәр Советының 2015 елның 23 июлендәге «Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге 21/8 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында 41/8 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2015 елның 29 июлендәге 54 нче санында бастырылган;

7) Шәһәр Советының 2017 елның 22 февралендәге «Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге 21/8 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында 15/8 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2017 елның 22 марттагы 19 нчы санында бастырылган;

8) Шәһәр Советының 2017 елның 29 мартындагы «Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге 21/8 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында 16/7 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2017 елның 26 апрелендәге 29 нчы санында бастырылган.

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының 20/8 санлы
Карарына кушымта
2017 ел, 24 октябрь

**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләре**

**I кисәк. Гомуми өлеш**

Әлеге Кагыйдәләр 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2002 елның 10 гыйнварындагы «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 7-ФЗ санлы Федераль закон, 1998 елның 24 июнендәге «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 89-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Төзелеш министрлыгының 2017 елның 13 апрелендәге «Җирлекләр, шәһәр округлары, шәһәр эчендәге районнар территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләрен әзерләү өчен методик рекомендацияләрне раслау турында» 711/пр санлы боерыгына нигезләнеп эшләнде.

**1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр**

1. Әлеге Кагыйдәләр Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерүгә, шул исәптән биналарны (торак йортларны да кертеп), корылмаларны һәм алар урнашкан җир участокларын карап тотуга, бина һәм корылма фасадларының һәм коймаларының тышкы кыяфәтенә бердәм таләпләр һәм нормаларны, төзекләндерү эшләре исемлеген һәм аларны башкару периодларын, шулай ук бина (торак) һәм корылма милекчеләренең якын-тирә территорияләрне төзекләндерүдә, төзекләндерү объектлары элементларын, шул исәптән, мәгълүмат конструкцияләрен, кече архитектура формаларын, ял итү урыннарын (мәйданчыкларны һәм ял итү зоналарын), автостоянка мәйданчыкларын, яшелләндерү элементларын, балалар мәйданчыкларын, спорт мәйданчыкларын, төзелеш мәйданчыкларын, хайваннарны урамда йөртү һәм аларны өйрәтү мәйданчыкларын, киртәләрне (коймаларны), тышкы яктырту объектларын (чараларын) планлаштыру, урнаштыру, төзекләндерү һәм карап тоту тәртибен билгели.

2. Әлеге Кагыйдәләр Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге (алга таба – муниципаль берәмлек) территориясендә барлык юридик һәм физик затлар тарафыннан үтәлергә тиеш.

3. Муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү түбәндәгеләр тарафыннан тәэмин ителә:

– Башкарма комитетның оештыру һәм контрольдә тоту функцияләрен башкаручы тармак (функциональ) органнары;

– муниципаль берәмлекне карап тоту һәм төзекләндерү эшләрен башкаручы оешмалар;

– юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр (алга таба – оешмалар), шулай ук шәхси мөлкәтне һәм әйләнә-тирә территорияләрне карап тотуны гамәлгә ашыручы гражданнар.

4. Төзекләндерү эшчәнлегендә түбәндәгеләр катнаша:

– муниципаль берәмлек халкы, төзекләндерү тәкъдимнәрен формалаштыра һәм тәкъдим ителгән карарларны бәяләүдә катнаша. Аерым очракларда, муниципаль берәмлек халкы эшләр башкаруда катнаша.

– җирле үзидарә органнары вәкилләре техник йөкләмәне формалаштыра, башкаручыларны сайлый һәм үз вәкаләтләре чикләрендә финанслауны тәэмин итә;

– муниципаль берәмлек территориясендә эшчәнлек алып баручы хуҗалык субъектлары төзекләндерү өчен тәкъдимнәр формалаштыруда, шулай ук төзекләндерү буенча чараларны финанслауда катнаша алалар;

– һөнәри берләшмә вәкилләре, шул исәптән төзекләндерү концепциясен һәм проектларын, эш документларын әзерләүче ландшафт архитекторлары, төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча белгечләр, архитекторлар һәм дизайнерлар;

– эшләрне башкаручылар, төзекләндерү һәм яшелләндерү, кече архитектура формаларын төзү буенча белгечләр;

– территорияне төзекләндерү белән кызыксынган башка затлар.

5. Физик һәм юридик затлар, оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә, хосусый яисә башка мөлкәти хокук нигезендә үз карамагындагы җир кишәрлекләрен әлеге Кагыйдәләр һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә үз вакытында һәм сыйфатлы җыештыруны һәм карап тотуны тәэмин итәргә тиеш.

**2 бүлек. Төшенчәләр һәм билгеләмәләр.**

6. Әлеге Кагыйдәләрдә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

1) **төзекләндерү** – муниципаль берәмлек территориясен карап тоту, халык яшәешенең сыйфатын тәэмин итү һәм аны тагын да яхшыртуга, территорияләрнең санитар һәм эстетик торышын тәэмин итү һәм яхшыртуга юнәлтелгән төзекләндәрү объектларын урнаштыру һәм проектлау чаралары комплексы;

2) **бункер-туплагыч** – күләме белән 2 куб метрдан зуррак булган эре габаритлы һәм башка чүпләрне туплау урыны;

3) **ишегалды территориясе** – җәмәгать биналары, бер яки берничә күп катлы торак йорт янәшәсендәге, аларда яшәүчеләр файдалануында булган һәм эшчәнлеген тәэмин итүче формалаштырылган территория. Ишегалды территориясендә балалар өчен мәйданчыклар, ял итү урыннары, кер киптерү урыны, автомобиль кую урыны, яшел утыртмалар һәм башка гомуми куллану объектлары урнаштырылырга мөмкин;

4) **балалар мәйданчыгы** – балалар уеннары өчен обьектлар (таучыклар, таганнар, карусельләр, комлыклар һәм (яки) башка шундый обьектлар) урнаштырылган җир участогы;

5) **газон** – каты өслек белән капланмаган, табигый яки ясалма үлән һәм (яки) агач-куаклыклар утыртылган яисә яшелләндерү исәпләнгән территория;

6) **яшел утыртмалар** – табигый яки ясалма үлән, агач һәм куаклыклар;

7) **җир эшләре** – тышкы төзекләндерү элементларын бозуга китереп, туфракны 30 см тирәнлектә казу (җир сөрү эшләреннән башка), биналарны, җир

асты һәм җир өсте инженерлык челтәрләрен, корылмаларны, гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары чикләрендә юл өсте катламы түшәү, ремонтлау һәм реконструкцияләү вакытында субай кагу, 50 см артыграк туфрак өстәү эшләрен (шул исәптән, аварияләрдән соң яңарту эшләрен) башкару;

8) **инженерлык коммуникацияләре** – су, җылылык, электр, газ белән тәэмин итү, канализация, яңгыр сулары канализациясе, су кабул итү һәм чыгару корылмаларын үз эченә алган җир өсте һәм җир асты коммуникацияләре һәм аларга бәйле җир өсте һәм җир асты обьектлары (корылмалары) һәм элементлары (коймалар, саклагыч катламнар, торбаүткәргеч терәүләре, кое һәм люк капкачлары, яңгыр сулары җыела торган коелар һәм вентиляция рәшәткәләре, төрле ярдәмче агрегатлар, су колонкалары);

9) **контейнер** – каты коммуналь калдыклар җыю өчен күләме белән 2 куб метрга кадәр булган махсус савыт;

10) **контейнер мәйданчыгы** – махсус җир кишәрлегендәге контейнер һәм бункерлар урнаштырылган чүп җыю һәм аны вакытлыча саклау мәйданчыгы;

11) **компенсацион яшелләндерү** – зарарланган яки юкка чыгарылган яшел үсентеләр урынына яңаларын утырту;

12) **кече архитектура формалары (алга таба– КАФ)** – монументаль-декоратив бизәү элементлары, мобиль һәм вертикаль яшелләндерү эшләрен башкару җайланмалары (беседкалар, аркалар, бакча-парк сыннары, вазоннар, чәчәклекләр, шпалерлар), су җайланмалары (фонтаннар, бюветлар, декоратив сулыклар), шәһәр җиһазлары (җәмәгать киңлекләрендә, рекреация зоналарында һәм ишегалларында ял итү өчен урнаштырылган эскәмияләр, мәйданчыкларда, сезонлы кафеларда өстәл уеннары өчен өстәлләр һәм эскәмияләр, урам һәм бакча җиһазлары), коммуналь-көнкүреш һәм техник җиһазлар (көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар, чүп савытлары, почта тартмалары, инженерлык җиһазлары элементлары), карау өчен люклар һ.б.;

13) **ордер** – җир һәм төзелеш эшләрен башкаруга хокук бирүче документ;

14) **тышкы яктырту объектлары (чаралары, яктырту җиһазлары)** – урам, сквер, паркларда, яктырткычлар өчен махсус куелган баганаларга, стеналарга, бина һәм корылма тышларына, бина һәм корылмаларның тимер-бетон һәм башка конструкцияләренә һәм җәмәгать куллануындагы башка урыннарга урнаштырылган яктырту җиһазлары (яктырткычлар, прожекторлар);

15) **төзекләндерү проекты** – җирлекне һәм объектларны төзекләндерү буенча (төсләрне дә кертеп эшләнгән) проект карарын үз эченә алган текст һәм график материаллар тупланган документ;

16) **хайваннарны йөртү һәм күнекмәләргә өйрәтү өчен мәйданчык** – хайваннарны йөртү һәм күнекмәләргә өйрәтү өчен билгеләнгән тәртиптә бирелгән җир кишәрлеге;

17) **машина кую мәйданчыгы** – нигездә җиңел автомобиль һәм башка мототранспорт чараларын (мотоцикллар, мотороллерлар, мотоколяскалар, мопедлар, скутерлар) саклау (вакытлыча куеп тору) өчен махсус ачык мәйданчык;

18) **яшел утыртмаларга зыян килү** – яшел утыртманың тамыр системасы һәм өске өлешенә механик, химик һәм үсүдән туктатмый торган башка төрле зарар китерү, шул исәптән, яшел утыртмаларга яисә туфракка зарарлы яки пычрак матдәләр белән зыян салу;

19) **төзекләндерү объектын карап тоту** – төзекләндерү объектларының һәм аларның аерым элементларының чисталыгын, техник, физик, санитар һәм экологик торышын тәэмин итү;

20) **территорияне карап тоту** – территорияне һәм төзекләндерү объектларын, аларның аерым элементларын тиешле техник, физик, санитар һәм экологик хәлдә тотуга һәм чистартуга юнәлтелгән чаралар комплексы;

21) **спорт мәйданчыгы** – физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү объектлары (баскетбол щитлары, борыслар, гимнастика өчен стена, турниклар һәм (яки) башка обьектлар) урнаштырылган җир участогы;

22) **төзелеш мәйданчыгы** – яңа күчемсез милек обьектлары (шул исәптән, төзелеш тәмамланмаган объектлар) төзү, шулай ук кулланудагы күчемсез милек обьектларын реконструкцияләү, техник яктан яңарту һәм (яки) ремонтлау, сүтү урыны, шулай ук корылмаларны техник яңарту, реконструкцияләү, төзү һәм (яки) җыю урыны;

23) **гомуми файдаланудагы территория** – чикләнмәгән затлар даирәсе тоткарлыксыз файдаланучы территорияләр (шул исәптән, мәйданнар, урамнар, тыкрыклар, яр буйлары, су обьектларының яр буе полосалары, скверлар, бульварлар һ.б.);

24) **каты коммуналь калдыклар** – торак биналарда физик затлар кулланудан хасил булган калдыклар, шулай ук физик затларның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү процессында куллану үзенчәлеген югалткан товарлар. Каты коммуналь калдыкларга юридик затлар һәм эшмәкәрләр эшчәнлеге нәтиҗәсендә хасил булган һәм физик затлар кулланудан барлыкка килгән калдыклар да керә;

25) **территорияне җыештыру** – территорияне даими рәвештә пычрактан, чүп-чардан, кардан, боздан чистартып, җитештерү һәм куллану һәм (яки) башка калдыкларны махсус урыннарга чыгару, шулай ук әйләнә-тирә мохитне һәм халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген саклауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән башка чаралар;

26) **урна** – чүп җыю өчен махсус савыт;

27) **төзекләндерү объектлары элементлары** – төзекләндерү объектларының визуаль ягын тәэмин итеп, аларның тышкы күренешен билгеләүче конструктив һәм функциональ нигездәге элементлар, шулай ук төзекләндерү объектларын функциональ билгеләнештә куллану (эксплуатацияләү);

28) **яшелләндерү элементлары** – скверлар, парклар, сәнәгать һәм торак төзелеше бинаалары каршында, иҗтимагый-административ үзәкләрдә, шулай ук урамннарда, магистральләрдә, яшелләндерү өчен билгеләнгән территорияләрдә яшелләндерелгән участоклар;

29) **өслекләрне тоташтыру элементлары** – төрле төрдәге ташлар, пандуслар, басмалар, баскычлар.

## II өлеш. Төзекләндерү объектларына, элементларына һәм аларны карап тотуга карата таләпләр

3 бүлек. Гомуми таләпләр

7. Торак мохитне, урамнарны, юлларны, мәдәни-көнкүреш хезмәт күрсәтү объектларын проектлаганда, төзекләндергәндә һәм карап тотканда халыкның аз мобильле төркемнәре өчен ачык мохит булдыруны күздә тотарга, шул исәптән, объектларны халыкның аз мобильле төркемнәре хәрәкәтенә булышлык итүче элементлар һәм техник чаралар белән җиһазларга кирәк.

8. Халыкның аз мобильле төркемнәре хәрәкәтенә булышлык итүче техник чаралар һәм җиһазларны проектлау, төзү, урнаштыру эшләре яңа төзелеш барышында заказчы тарафыннан һәм расланган документлар нигезендә башкарыла.

9. Муниципаль берәмлекнең гомуми кулланудагы территорияләрендә түбәндәгеләр тыела:

1) территорияләрне тимер-томыр, төзелеш һәм көнкүреш чүп-чары, шлак һәм башка калдыклар белән чүпләү, ягулык-майлау материаллары, нефть продуктлары белән пычрату, калдыклардан чүп өеме өю;

2) махсус билгеләнгән урыннардан һәм калдыкларны җыю контейнерларыннан тыш башка урыннарга калдыклар һәм чүп-чар тутыру;

3) билгеләнгән тәртипне бозып, стационар сәүдә обьектлары, ял итү өлкәсендә хезмәт күрсәтү сферасы обьектлары (халыкның ялын оештыру һәм күңел ачу аттракционнары, кабартылган батутлар, роликлар, велосипедлар һәм башка шундый объектлар) урнаштыру;

4) яшел утыртмаларда (агачларда, куаклыкларда, су торбаларында, урамдагы коймаларда, асфальт һәм плитәләрдә һәм башка каралмаган урыннарда) реклама һәм мәгълүмат материаллары урнаштыру;

5) махсус билгеләнгән урыннардан тыш башка җирдә автотранспорт чараларын юу һәм чистарту;

6) бу максатлар өчен махсус җиһазландырылмаган машиналарда юлларны пычратудан саклаучы брезент һәм башка каплау чарасын кулланмыйча, коела торган, тузансыман йөкләр, эремәләр, корыган яфрак, калдыклар, сыек йөкләр ташу;

7) стационар булмаган сәүдә обьектларын рөхсәтсез урнаштыру;

8) җир эшләрен рөхсәт язуы (ордер) булмыйча башкару;

9) туфрак, чүп-чар, калдыклар, кар, бозны бу максатка каралмаган урыннарга чыгару;

10) гамәлдәге законнарны бозып, төзү материалларын урамнарда, тротуарларда, газоннарда тоту, квартал эчендәге юлларны һәм йорт яны юлларын ябу;

11) газоннар, тротуарлар, урамнар, мәйданнар, ишегалды территорияләре, парклар, скверлар һәм башка җәмәгать урыннарында тәмәке төпчекләре, кәгазь, чүп ташлау;

12) бакча диваннарының, эскәмияләренең артына утыру, урналарны, урамны яктыртучы фонарьларны, башка кече архитектура формаларын пычрату, аларга зыян салу яки вату;

13) себерелгән чүпне һәм көнкүреш калдыкларын кое капкачлары, яңгыр сулары канализациясенең су агып төшә торган рәшәткәләре өстенә, улак һәм кюветларга ташлау;

14) чүп, корыган яфрак һәм үләнне, буш савытларны, җитештерү калдыкларын, каты коммуналь калдыкларны яндыру, учак ягу, шул исәптән, янгынга каршы чаралары булмаган (ябык савытлар һәм янгын сүндерү чаралары) предприятие һәм шәхси хуҗалыклар эчендә;

15) тиеш булмаган урыннарда урам сәүдәсе оештыру;

16) рөхсәтсез фасадларны үзгәртү, барлык типтагы гаражларны урнаштыру, билгеләнмәген урыннарда тышкы мәгълүмат чараларын, кече архитектура формаларын урнаштыру;

17) яшел утыртмаларны сындыру, бозу, юк итү, кәүсәләрне рөхсәтсез кисү, агачларга кадак кагу, гамаклар һәм таганнар, кер баулары элү;

18) газоннарга зыян китерү һәм аларны юк итү.

## 4 бүлек. Балалар мәйданчыклары

10. Балалар мәйданчыкларының билгеләнеше – төрле яшьтәге балаларның: нәниләр (3 яшькә кадәр), мәктәпкәчә (7 яшькә кадәр), кече һәм урта яшьтәге мәктәп балалары (7-12 яшь), яшүсмерләрнең (12-16 яшь) уеннарын һәм актив ялын оештыру. Балалар мәйданчыклары төрле яшь төркемнәре буенча аерым мәйданчыклар яки яшь үзенчәлекләре буенча зоналарга бүленгән уен мәйданчыклары комплексы итеп оештырылырга мөмкин.

11. Мәйданчыкларның зурлыгы һәм урнаштыру шартлары балаларның яшь төркемнәренә һәм муниципаль берәмлектә торак төзелеше урынына карап проектлана.

12. Балалар мәйданчыкларын урнаштыру инженерлык коммуникацияләре хуҗалары белән килештерелергә тиеш.

13. Балалар мәйданчыклары транзит җәяүлеләр юлыннан, машина юлыннан, борылыш мәйданчыкларыннан, машина кую урыннарыннан, чүп җыю савытлары кую урыннарыннан, автотранспорт чараларын вакытлыча һәм даими саклау урыннарыннан араланган булырга тиеш.

## 5 бүлек. Спорт мәйданчыклары

14. Спорт мәйданчыкларының билгеләнеше – халыкның яшь буенча барлык төркемнәре өчен физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү. Аларны торак һәм рекреацион билгеләнештәге территорияләр, спорт корылмалары участокларында, мәгариф учреждениеләре участокларында проектларга кирәк.

15. Яшелләндерү эшләрен, мәйданчык кырыннан 2 м дан да ким булмаган ераклыкта, тиз үсүче агачлар утыртып, мәйданчык периметры буенча башкару шарт. Ялтыравык яфраклы, күп күләмдә җимешләр, оча торган орлыклар бирүче, яфракларын иртә коючы агачлар һәм куаклар утыртырга киңәш ителми. Мәйданчыкны вертикаль яшелләндерү ысулы белән киртәләргә кирәк.

16. Мәйданчыкларда 2,3 – 3 м биеклектә, ә бер-берсенә чиктәш спорт мәйданчыклары чикләрендә 1,2 м дан да ким булмаган биеклектәге сеткалы җайланма урнаштырылырга тиеш.

17. Спорт мәйданчыкларын урнаштыру инженерлык коммуникацияләре хуҗалары белән килештерелергә тиеш.

6 бүлек. Ял итү мәйданчыклары

18. Өлкәннәр өчен ял итү мәйданчыклары торак төзелеше участокларында, микрорайоннарның яшелләндерелгән территорияләрендә, паркларда һәм урман-паркларда урнаштырыла.

19. Ял мәйданчыкларында булырга тиешле төзекләндерү элементлары исемлеге: каты өслек, мәйданчык өслеген газон белән чикләү элементлары, ял итү өчен эскәмияләр, эскәмия һәм өстәлләр, урналар (һәр эскәмия янында минимум берәү), яктырту җиһазлары.

20. Яктырту җиһазларының эшен мәйданчык урнашкан территорияне яктырту режимында тәэмин итү шарт.

21. Ял мәйданчыкларын инвалидлар һәм халыкның аз мобильле төркемнәре хәрәкәтенә булышлык итүче җайланмалардан башка планлаштыру һәм җиһазлау рөхсәт ителми.

22. Мәйданчык өслеген проектлаганда плитә түшәү ысулын кулланырга кирәк. Ял мәйданчыгын балалар мәйданчыгы белән бергә эшләгәндә, балалар уеннары зонасында каты өслек җәю рөхсәт ителми.

23. Ял итү территориясе көн саен чүптән һәм ят предметлардан чистартыла. Агач һәм куакларны кисү, үлән чабу эшләре үзвакытында башкарыла.

24. Ял итү урыннарында юллар, коймалар, эскәмияләр, чүп савытлары төзек хәлдә булырга тиеш. Урналардагы чүпне, ким дигәндә, тәүлеккә бер тапкыр, иртәнге сәгатьләрдә җыярга тәкъдим ителә.

25. Ял итү урыннарында тышкы яктырту чаралары төзек хәлдә, яктырту баганалары һәм җиһазлары механик яктан зарарланмаган, тутыкмаган, плафоннар чиста, ярыксыз һәм китексез булырга тиеш.

7 бүлек. Этләрне йөртү һәм (яки) күнекмәләргә өйрәтү өчен мәйданчык

26. Этләрне йөртү һәм (яки) күнекмәләргә өйрәтү өчен мәйданчыклар яшел утыртмалары булмаган, 1 нче класслы гомумшәһәр магистраль линияләренең техник зоналарында, көчәнеше 110 кВт тан артмаган электр тапшырулар линиясе астында, беренче һәм икенче пояслы су белән тәэмин итү чыганакларының санитар зонасыннан тыш гомуми файдаланудагы территорияләрдә урнаштырыла.

27. Торак билгеләнешендәге территорияләрдә этләрне йөртү һәм (яки) күнекмәләргә өйрәтү өчен урнаштырылган мәйданчыкларның мәйданы 400-600 кв.м, башка территорияләрдә 800 кв.мга кадәр булырга, төзелеш тәмамланган урыннарда, территориаль мөмкинлекләрне исәпкә алып, мәйданчыкның зурлыгы кимрәк тә булырга мөмкин. Мәйданчыкларга бару юлы 400 метрдан, төзелеш объектлары тыгыз урнашкан территорияләрдә 600 метрдан артык булмаска тиеш. Мәйданчык чигеннән торак һәм җәмәгать биналары тәрәзәләренә кадәр ара 25 метрдан, балалар учреждениеләре, мәктәпләр, балалар, спорт мәйданчыклары, ял мәйданчыкларына кадәр 40 метрдан ким булмаска тиеш.

28. Этләрне йөртү һәм (яки) күнекмәләргә өйрәтү өчен мәйданчыклар урнаштыру урыннарын Башкарма комитет билгели.

8 бүлек. Машина кую мәйданчыклары

29. Муниципаль берәмлек территориясендә түбәндәге төрдәге машина кую урыннары булдыру карала: кыска вакытлы һәм озак вакытка исәпләнгән машина саклау урыны, урам, урамнан тыш (юл янындагы чигенеш яки «кесә» формасында); кунаклар өчен (торак төзелеше участогында); халыкның шәхси автомобильләрен саклау өчен (микрорайоннарда); объект янында (бер объект яки объектлар төркеме янында); башка төрле (авыр йөк машиналары өчен һ.б.).

30. Халыкка хезмәт күрсәтү учреждениеләре янындагы ачык машина кую урыннарының инвалидлар транспорты өчен билгеләнгәнен санитария нормаларына һәм кагыйдәләргә нигезләнеп проектларга кирәк.

31. Машина кую мәйданчыклары территориясен төзекләндерүнең мәҗбүри элементлары: каты өслек (тимер-бетон, бетон, асфальт-бетон, таш, грунт катламы), өслекләрне тоташтыру элементлары, коймалар, урналар яки чүп-чар өчен кечкенә контейнерлар, яктырту һәм мәгълүмат бирү җиһазлары. Автомобильләрне озак вакыт саклау мәйданчыкларын әвеслек, җиңел корылмалы бокслар, карау өчен эстакада белән җиһазларга мөмкин.

32. Җәмәгать киңлекләрен һәм ишегалды территорияләрен планлаштырганда газоннарга транспорт чараларын куюны чикләүче максус каршылыкларны исәпкә алу рөхсәт ителә.

33. Машина кую мәйданчыкларын урнаштыру инженерлык коммуникацияләре хуҗалары белән килештерелергә тиеш.

9 бүлек. Каты коммуналь калдыкларны җыю контейнерларын урнаштыру мәйданчыклары

34. Контейнер мәйданчыкларында һәм коммуналь калдыкларның аерым төрләрен җыю мәйданчыкларында калдыкларны алып китүнең вакыты, бу эшне башкаручы оешманың исеме, мәйданчыкны карап тоту һәм калдыкларны вакытында алып китү өчен җаваплы затның контактлары, шулай ук автотранспорт хуҗалары өчен контейнерларга хезмәт күрсәтүче махсус автомобиль хәрәкәтенә каршылык тудырмау хакында кисәтүле мәгълүмат булу шарт.

35. Әлеге мәйданчыкларны урнаштыру коммуналь калдыклар туплану мөмкинлеге булган төрле функциональ билгеләнештәге территорияләрдә һәм участокларда күздә тотыла.

36. Контейнер мәйданчыгы зурлыгын калдыклар тупланучы контейнерларның санына, үлчәменә карап һәм билгеләнгән санитар-эпидемиологик шартлар кысаларында билгеләү зарур.

37. Күп фатирлы йорт милекчеләрнең гомуми милке составына кертелгән, йорт яны территориясендә урнашкан контейнер мәйданчыкларын карап тоту өчен идарәче оешмалар, торак милекчеләре ширкәте (торак кооперативы) җаваплы.

38. Күп фатирлы йорт милекчеләрнең гомуми милке составына кермәүче контейнер мәйданчыкларын карап тоту өчен контейнер мәйданчыклары урнашкан җир кишәрлекләре хуҗалары җаваплы.

10 бүлек. Урамнар (шул исәптән җәяүлеләр өчен) һәм юллар

39. Гомуми кулланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, гомуми кулланудагы автомобиль юллары төзү элементларын төзекләндерү чаралары 2007 елның 8 ноябрендәге «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнләге һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 257-ФЗ санлы Федераль законга һәм Россия Федерациясенең гомуми кулланудагы автомобиль юлларына карата таләпләрне билгеләүче норматив хокукый актларына һәм норматив-техник документларына каршылык тудырмаска тиеш.

40. Муниципаль берәмлек территоряисендә җәяүлеләр өчен коммуникацияләр төзегәндә һәм төзекләндергәндә түбәндәгеләрне тәэмин итү шарт: транспорт коммуникацияләре белән киселеш минималь санда булу, җәяүлеләр коммуникацияләре системасы өзлексез булу, җәяүлеләрнең, инвалидларны һәм халыкның аз мобильле төркемнәрен дә кертеп, хәвефсез, каршылыксыз һәм хәрәкәт итәргә уңай һәм яшелләндерү мөмкинлеге булу.

41. Җәяүлеләр өчен тротуарлар төзүне планлаштырганда санитария кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә инвалидлар һәм хәрәкәтләнү мөмкинлеге чикле булган затлар һәм аларны озатып йөрүчеләр өчен биналарга һәм корылмаларга каршылыксыз керү шартлары тудыруны, шулай ук халыкның аз мобильле төркемнәре өчен махсус җиһазландырылган урыннарны исәпкә алу шарт.

42. Урамнарны һәм юлларны төзекләндерүнең төп элементлары исемлегенә түбәндәгеләр керә: юл һәм тротуарларның каты өслеге, өслекләрне тоташтыру элементлары, юл буе һәм тротуарлар янының яшелләндерелүе, урналар һәм чүп өчен кечкенә контейнерлар, эскәмияләр, куркыныч урыннарны әйләндереп алу, яктырту җиһазлары, юл хәрәкәте мәгълүматы (юл билгеләре, светофорлар).

43. Юл катламының төрләре һәм конструкцияләре урам категориясен һәм хәрәкәт куркынычсызлыгын тәэмин итүне исәпкә алып проектлана.

44. Урамнарны һәм юлларны яшелләндерү проектын эшләгәндә, төзелеш кагыйдәләрендә каралганча, җир асты коммуникация челтәрләреннән һәм урам-юл челтәренең башка корылмаларыннан яшел утыртмаларга кадәр ара минималь ераклыкта булырга тиеш.

45. Урам-юл челтәрен җыештыру өчен түбәндәгеләр җаваплы:

- аукцион нәтиҗәләре буенча билгеләнгән подрядчы оешма, муниципаль контрактның техник йөкләмәсендә каралган тәртиптә;

– ремонт-яңарту эшләре алып барганда, инженерлык коммуникацияләре челтәрләре милекчесе (эксплутацияләүче оешма) – инженер коммуникацияләре челтәрендә авария урынында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өчен шартлар тудыруга җаваплы.

11 бүлек. Катламның төрләре

46. Өслек катламнары муниципаль берәмлек территориясендә хәрәкәт куркынычсызлыгын һәм уңайлыгын тәэмин итә, шулай ук әйләнә-тирәлекнең архитектура-сәнгати йөзен формалаштыра.

47. Проектта ремонтка яраклы, экологик, шумый торган катлам билгеләү шарт.

12 бүлек. Парклар, скверлар һәм башка яшел зоналар

48. Парклар, скверларның билгеләнеше – кыска вакытлы ял оештыру, ял итеп йөрү, җәяүлеләрнең транзит хәрәкәте.

49. Парклар һәм скверлар территорясендә төзекләндерү элементлары мәйдан һәм юлларның каты өслеген, өслекләрне тоташтыру элементларын, яшелләндерү, эскәмияләр, урналар яки чүп өчен кечкенә контейнерлар, яктырту җиһазлары, архитектура-декоратив яктырту җиһазларын үз эченә ала.

50. Паркларны, скверларны яшелләндергәндә эчке территорияне урамнардан аерып торучы утыртма полосалары куллану карала: эре җәмәгать биналары каршында фонтан һәм чәчәклекләр белән ял өчен мәйданчыклар урнаштыру тәкъдим ителә.  Скверларны яшелләндергәндә пространствоны визуаль зурайтып күрсәтү ысуллары кулланыла.

51. Парклар, скверлар һәм башка яшеллек зоналары көн саен чүп-чардан һәм чит предметлардан чистартыла. Агач һәм куаклыкларны кисү зарурлыктан чыгып башкарыла.

52. Паркларда, скверларда һәм башка яшеллек зоналарында юллар, коймалар, эскәмияләр, чүп савытлары төзек хәлдә булырга тиеш. Чүп савытындагы чүпне зарурлыктан чыгып, кимендә тәүлеккә бер тапкыр бушатырга тәкъдим ителә.

53. Парклар, скверлар һәм башка яшеллек зоналарында тышкы яктырту чаралары төзек хәлдә булырга, яктырту арматурасы һәм (яки) яктырту баганасы механик зарарланмаган, тутыкмаган, плафоннар чиста һәм төзек булырга тиеш.

13 бүлек. Яшелләндерү

54. Яшелләндерү – булган һәм (яки) булдырылган табигый комплексларны актив кулланып, муниципаль берәмлекнең тотрыклы мохитен формалаштыруны тәэмин итүче территориянең ландшафтын оештыру һәм төзекләндерүнең төп һәм мөһим өлеше, шулай ук элек утыртылган яки табигый әйләнә-тирәлекне саклау һәм карап тоту.

55. Яшелләндерү эшләре муниципаль берәмлекне төзекләндерү объектларын төзү, аларга капиталь ремонт, реконструкция үткәрүгә проект документлары эшләгәндә планлаштырыла.

56. Агач һәм куакларны, шул исәптән корыган һәм авыру агач һәм куакларны кисү муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә бирелгән рөхсәт нигезендә башкарыла.

57. Гадәттән тыш хәлләрдә һәм авария очракларында, агач авып, кеше тормышына һәм сәламәтлегенә, бина һәм корылмаларга, транспорт хәрәкәтенә, коммуникацияләр эшчәнлегенә зыян салу куркынычы килеп туганда, күрсәтелгән утыртмаларны кисү рөхсәтсез башкарыла.

58. Объектларда һәм (яки) инженерлык коммуникацияләрендә кичектергесез ремонт таләп иткән авария очракларында, яшел утыртмаларны кисү алдан рөхсәт алмыйча башкарыла, бу очракта Башкарма комитетка хәбәр итү шарт.

14 бүлек. Кече архитектура формалары (КАФ) һәм урам җиһазлары

59. Кече архитектура формалары (алга таба – КАФ) ясаганда һәм төзекләндергәндә функциональ төрлелек принципларын, буш пространство булуын, җәяүлеләр һәм транспорт хәрәкәте ешлыгын, транспорт төеннәренең якынлыгын, территориядә көн саен булучы халык санын исәпкә алу шарт. Объектның материалын һәм дизайнын эксплуатацияләү шартларын исәпкә алып проектлау мөһим.

60. КАФ проектлаганда, сайлаганда түбәндәгеләрне исәпкә алырга кирәк:

1) КАФ материалларының һәм конструкциясенең климатка һәм КАФ билгеләнешенә туры килүен;

2) вандаллардан (ватылудан, сурәт төшерү һәм рәсем ясаудан һ.б.ш.) сакланышын;

3) КАФ детальләрен ремонтлау яки алыштыру мөмкинлеген;

4) боз һәм кар белән капланудан саклауны, кар һәм яңгыр сулары агышын тәэмин итүне;

5) карап тотуның уңайлы булуын, шулай ук КАФ белән янәшә, конструкция астындагы территорияне механик һәм кул көче белән чистарту мөмкинлеген;

6) конструкцияләрнең уңайлы булуын (биеклеге, авышлыгы, урналарның биеклеге);

7) әйләнә-тирәлек белән каршылыкка килмәүче төстә булуын;

8) потенциаль файдаланучылар өчен куркынычсыз булуын;

9) якын-тирәдәге архитектура һәм башка КАФлар белән стилистик ярашлы булуын;

10) урнашу зонасы характеристикаларына туры килүен: юллар, тротуарлар өчен утилитар, минималистик дизайн, рекреация зоналары һәм ишегаллары өчен – катлаулырак, декор элементлары белән эшләнгән дизайн.

61. КАФ урнаштыру өчен гомуми таләпләр:

1) җәяүлеләр өчен каршылык тудырмау;

2) халык күп җыела торган урыннарда, минималь мәйданнарда компактлы итеп урнаштыру;

3) конструкциянең тотрыклы булуы;

4) урнашу үзенчәлегенә карап, башка урынга күчерү мөмкинлеге булу яисә каты нигезгә урнаштыру;

5) һәр конкрет зонада шундый зонада урнаштыру өчен тәкъдим ителгән КАФ булу.

62. Урналар урнаштыруга карата таләпләр:

1) тиешле биеклектә (максималь – 100 см га кадәр) һәм күләмдә булу;

2) график вандаллыктан саклау өчен префорация яисә рельефлы өслекле булуы;

3) яңгыр һәм кардан сакланган булуы;

4) чүп чиләкләренең һәм махсус капчыкларның пөхтә куелган булуы, аларны кулланганда пөхтәлек саклау.

63. Җәмәгать киңлекләрендә, рекреация зоналарында һәм ишегалларында урнаштырылган урам җиһазларына, шул исәптән ял итү эскәмияләренә, өстәл уеннары өчен мәйданчыклардагы эскәмия һәм өстәлләргә, җәйге кафеларга һ.б. карата таләпләр:

1) эскәмияләрне каты өслеккә яисә фундаментка урнаштыру шарт. Ял зоналарында, балалар мәйданчыкларында йомшак өслеккә урнаштыру рөхсәт ителә. Фундамент булган очракта, аны җирдән калкып тормаслык итеп эшләргә тәкъдим ителә.

2) рекреация зоналарындагы эскәмияләрнең артлы, ишегаллары зоналарындагы эскәмияләрнең артлы һәм култыксалы, транзит зоналардагы эскәмияләрнең артсыз һәм култыксаларсыз булуы шарт;

3) аеруча саклануга мохтаҗ табигать территорияләрендә очлы һәм ярык булмаган агач бүкәннәреннән, бүрәнә һәм бүрәнә кисәкләреннән өстәл һәм эскәмияләр ясарга мөмкин.

64. Чәчәклекләрнең (газоннарның), шул исәптән, асылмалыларның биеклеге автомобиль килеп бәрелүдән һәм чүп-чар төшүдән сакланган булырга тиеш.

65. Коймалар урнаштырганда түбәндәгеләрне исәпкә алырга кирәк:

1) җәяүлеләрне автомобиль бәрдерүдән сакларлык дәрәҗәдә нык булу;

2) төрле формадагы конструкцияләр ясарга мөмкинлек бирә торган дәрәҗәдә модульле булу;

3) автомобиль бәрелүе мөмкин булган урыннарда яктылыкны кире кайтаргыч элементлар урнаштыру;

4) койма газоннан 10 см дан да ераграк булмаска тиеш;

5) нейтраль төсләр яки материалның табигый төсен куллану.

66. Автомобиль юллары янындагы тротуарларда түбәндәге КАФ урнаштырырга кирәк:

1) сумка кую урыннары булган артсыз эскәмияләр;

2) физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен эскәмияләр янында махсус терәкләр;

3) җәяүлеләрне автомобиль бәрдерүдән саклаучы корылмалар;

4) асылма кашпо, чәчәклек һәм вазоннар;

5) биек чәчәклекләр (вазоннар) һәм урналар.

67. Шәһәр җиһазларын әйләнә-тирәдәге архитектура үзенчәлегеннән чыгып сайларга кирәк.

68. Заманча дизайндагы шәһәр җиһазлары, югары сыйфатлы булган очракта, аларны тарихи төзелеш зоналарында кулланырга мөмкин. Заманча төзелеш зоналарында тарихи стильдәге җиһаз куллану киңәш ителми.

69. Җәяүлеләр зонасында түбәндәге КАФ ларны кулланырга кирәк:

1) урам фонарьлары, аларның биеклеге кеше буе чагыштырмасында билгеләнә;

2) озак вакыт утырып торуга исәпләнгән эскәмияләр;

3) чәчәклекләр һәм кашполар (вазоннар);

4) мәгълүмат стендлары;

5) саклау коймалары;

6) уен өчен өстәлләр.

70. КАФ өслеген минималь итеп, буш өслекләрне график вандаллыктан саклау һәм чистартуны җиңеләйтү өчен рельефлы яки перфорацияләнгән итеп эшләргә кирәк.

71. Тоташ коймаларны аралы коймаларга алыштыру зарур. Койманы сүтәргә яки аны аралы итеп үзгәртергә мөмкинлек булмаган очракта, визуаль (контраст

сурәтле стрит-арт кулланып) үзгәртергә яки яшел утыртмалар белән капларга кирәк.

72. Кечкенә объектларны (коммутация шкафларын һәм башкаларны) кече форматлы реклама өслегендә урнаштыру зарур. Афиша тумбасы эчендә стрит-арт урнаштырырга мөмкин.

73. График вандаллыктан саклау максатыннан, яктырту баганаларын һәм башка объектларны рельефлы итеп, шул исәптән, рельеф кисәкчекләре булган буяу куллануны күздә тотып проектларга кирәк.

74. Потенциаль вандаллыктан саклау өчен (вандаллыкның төп зонасы – җирдән 30-200 сантиметр биеклек икәнен исәпкә алып) мәгълүмат конструкцияләрен иҗтимагый файдалы мәгълүмат, мәсәлән, җирлекнең тарихи планы, навигация схемасы һәм башка шундый элементлар белән бергә урнаштырырга мөмкин.

75. Җиһазны проектлаганда һәм урнаштырганда аның вандаллардан сакланышын исәпкә алу зарур, шул исәптән:

1) җиңел чистартылучы, абразив һәм эрүләргә каршы торырга сәләтле материаллар куллану;

2) КАФ һәм җиһазның яссы өслекләрендә игъланнар беркетүгә һәм өслеккә рәсем ясауга комачаулык тудыручы һәм чистарту эшен җиңеләйтүче перфорацияләнгән яисә рельефлы текстура куллану;

3) караңгы төстәге буяулар һәм материаллар куллану.

76. Объектларны әйләнә-тирә мохиткә максималь рәвештә нейтраль итеп (мәсәлән, нейтраль төсне – кара, соры, ак, шулай ук башка төсләрнең караңгырак төсмерләрен кулланып) эшләү зарур.

15 бүлек. Коймалар

77. Коймалар корганда һәм төзекләндергәндә функциональ төрлелек, җәяүлеләр өчен уңайлы мохит булдыру, халыкның ярымприват пространстволарга (кереп йөрү өчен ачык, әмма, нигездә, социаль аралашу яки күчемсез милектән бергә файдаланучы затлар төркеме файдаланучы пространство) ихтыяҗын канәгатьләндерү максатыннан, табигать белән гармонияле булу, халык өчен кирәкле булган җәяүле маршрутлар челтәрен саклау, куркынычсызлык таләпләре нигезендә газоннарны һәм гомуми куллanудагы яшел утыртмаларны саклау принципларын исәпкә алу зарур.

78. Җәмәгать, торак, рекреацион билгеләнештәге территорияләрдә металлдан челтәрләп эшләнгән декоратив коймалар кулланырга, тоташ, ябык һәм тимер-бетон коймаларны (шул исәптән, күп катлы йортлар янындагы коймаларны проектлаганда) кулланмаска киңәш ителә.

79. Җәяүлеләрнең интенсив хәрәкәт урыннарында яки ремонт һәм төзелеш зоналарында агачлар үскәндә, башка төрдәге саклау чаралары булмаган очракта, кәүсәләр янында биеклеген агачның төренә һәм башка характеристикаларына бәйле рәвештә билгеләп, саклагыч коймалар урнаштыру зарур.

80. Коймалар корганда һәм төзекләндергәндә түбәндәгеләрне исәпкә алырга кирәк:

1) яшел зонаны (газоннар, клумбалар, парклар) җәяүлеләр һәм транспорт маршруты зонасыннан аеруны;

2) юл һәм тротуарларны проектлауны халык һәм транспорт маршрутлары хәрәкәтенең ешлыгын исәпкә алып башкаруны;

3) яшел зоналарны һәм транзит юлларны төрле биеклек алымын кулланып яисә яшел куаклыклар утыртып чикләүне;

4) бордюр ташының биеклеген һәм геометриясен сезонлы кар катламын исәпкә алып проектлауны;

5) бордюр ташын куллануны;

6) җирлекнең архитектура үзенчәлеге һәм яшелләндерелгән зонаның кечкенә булуы сәбәпле, койма тотып булмаган урында таш түшәүне;

7) күпъеллык куе куаклыклар куллануны (яшел зоналар чигендә);

8) газоннарның күләгәле өлешендә яктылыкны кире кайтаргыч фасад конструкцияләрен куллануны;

9) җирле архитектура органнары тарафыннан расланган төсләр палитрасындагы төс һәм графиканы (табигый төстәге материалларны, мәсәлән, таш, металл, агач һ.б.), нейтраль төсләрне (кара, соры, ак, шулай ук башка төсләрнең караңгырак төсмерләре) куллануны.

16 бүлек. Су җайланмалары

81. Су җайланмаларына фонтаннар, су эчү өчен кечкенә фонтанчыклар, бюветлар, чишмәләр, декоратив сулыклар керә. Су җайланмалары декоратив-эстетик функцияне үтиләр, һава һәм акустик мохитне яхшырталар. Барлык төрдәге су җайланмаларын да артык суны дренаж челтәргә яки яңгыр сулары канализациясенә чыгара торган торбалар белән тәэмин итү зарур.

82. Фонтаннарны билгеләнгән тәртиптә килештерелгән шәхси архитектура проектлары нигезендә проектлау зарур.

17 бүлек. Урам коммуналь-көнкүреш җиһазы

83. Урам коммуналь-көнкүреш җиһазларына төрле төрдәге чүп җыю савытлары – бункер-туплагычлар, контейнерлар, урналар керә. Урам коммуналь-көнкүреш җиһазын сайлаганда төп таләпләр түбәндәгеләр: алар экологиягә яраешлы, куркынычсыз, куллану өчен уңайлы, чистарту өчен җайлы, тышкы яктан пөхтә булуы.

84. Муниципаль берәмлекләр территориясендә (урамнарда, мәйданнарда, рекреация объектларында) коммуналь калдыкларны туплау өчен контейнерлар һәм (яки) урналар кулланыла. Рекреация объектлары территориясендә контейнер һәм урналарны эскәмияләр, азык-төлек сату юнәлешендәге капиталь һәм стационар булмаган корылмалар һәм урамдагы техник җиһазлар янына урнаштыруны күздә тотарга кирәк. Моннан тыш, урналарны җәмәгать транспорты тукталышларында урнаштырырга киңәш ителә. Барлык очракта да, урналарны җәяүлеләр, инвалид һәм балалар коляскалары хәрәкәтенә комачаулык тудырмаслык итеп урнаштыру зарур.

85. Контейнерларның саны һәм зурлыгы җитештерү һәм куллану калдыклары турындагы законнар нигезендә билгеләнә.

18 бүлек. Урам техник җиһазы һәм инженерлык коммуникацияләре (линия корылмалары)

86. Урам техник җиһазларына кое люклары, яңгыр суы коелары рәшәткәләре, җир асты коммуникацияләренең вентиляция шахталары, телефон элемтәсе шкафлары һ.б. керә.

87. Инженерлык корылмалары элементлары техник шартларга каршылык тудырмаска тиеш, шул исәптән:

1) җәяүлеләр коммуникацияләре территориясендәге (шул исәптән урам киселешләрендә) карау коеларының люк капкачлары өслек белән бер биеклектә булып, аерма 20 мм дан, люк кырые һәм тротуар арасындагы ярык 15 мм дан артмаска тиеш.

2) җир асты коммуникацияләренең вентиляция шахталарына рәшәткә урнаштырырга кирәк.

88. Тышкы инженерлык коммуникацияләре (җылылык челтәрләре, газүткәргеч, электр челтәрләре, сүүткәргечләр һ.б.) һәм җыелган яңгыр суларын чыгаруның үзәк системасы төзек хәлдә булырга тиеш.

89. Яңгыр сулары һәм карау коеларының, җылылык трассасы, газ, ягулык, сүүткәргечләр, электр тапшыру линияләре һәм аларның изоляцияләре, башка корылма һәм коммуникацияләрнең җир өстендәге өлешләренә зыян килмәскә тиеш.

90. Урам һәм тротуарлардагы люк һәм кое капкачлары булмаган яки ватылган очракта, алар койма белән уратылып алынырга һәм өч көн эчендә коммуникацияләрне карап тотучы оешмалар тарафыннан төзәтелергә тиеш.

91. Җылылык, салкын су белән тәэмин итү һәм яңгыр сулары канализациясен эксплуатацияләүче оешмалар урам һәм тротуарлардагы карау һәм башка коеларның, камераларның люк капкачларын, газ коверларын асфальт-бетон өслек белән бер дәрәҗәдә тотарга тиеш. Моның өчен эксплуатацияләүче оешмалар даими рәвештә аларны тикшереп торырга тиеш. Өслек җимерелгәндә, оешмалар аны кое авызыннан 1 м итеп, үзенчәлеге, төре һәм маркасы буенча аналогик материал кулланып, төзәтергә тиеш. Асфальт-бетон өслекне җәю алдыннан вибрацияле утрамбовка үткәрү зарур. Яңа җәелә торган өслекнең элеккеге өслеккә ялганган урыны адгезив пластик материал белән эшкәртелергә тиеш. Яңа җәелгән өслекнең элеккеге өслек белән тоташкан урынында үлчәм буенча тайпылышлар булырга тиеш түгел.

92. Карау һәм яңгыр сулары коеларының люкларсыз булуы, люкларның пычраклыгы, газ -, ягулык-, сүүткәргечләр, линия корылмалары һәм коммуникацияләренең җир өсте өлешләрендә тышкы изоляциясе булмау, күрсәтелгән объектларның ремонтсыз булуы, профилактик тикшерүләрне, чистарту, буяу эшләрен вакытында башкармау рөхсәт ителми.

93. Юридик затларга караган су бирү корылмаларына юл хезмәтләре яисә тиешле оешмаларның башка структур бүлекчәләре тарафыннан хезмәт күрсәтелә.

94. Торак фондына хезмәт күрсәтүче оешмалар хезмәт күрсәтелә торган территориядә урнашкан карау коелары люкларына һәм инженерлык челтәрләре

белән идарә итү узелларына, шулай ук янгын сүндерүчеләрне су белән тәэмин итү чыганакларына (янгын гидрантлары, сулыклар) ирекле керү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

95. Квартал эчендәге һәм йорттагы линияле корылмалар челтәрләрен һәм коммуникацияләрне эксплуатацияләүнең нормаль шартларын саклау максатында, физик һәм юридик затларга түбәндәгеләр тыела:

1) кое люкларын ачу һәм суүткәргеч, канализация, җылылык трассасы магистральләрендә ябу җайланмаларын көйләү;

2) эксплуатацияләүче оешмалар рөхсәтеннән башка бу челтәрләрдә нинди дә булса эшләр башкару;

3) урам, ишегалды челтәрләре өстендә даими характердагы төзелешләр, инженерлык коммуникацияләре трассаларын төзелеш материаллары, чүп-чар белән каплау һ. б. ш.;

4) коеларны ябып бетермичә калдыру һәм (яки) ватык капкач белән каплау;

5) җир өстендәге суларны канализация системасына җибәрү;

6) янгын гидрантларыннан хуҗалык максатларында файдалану;

7) шланг ярдәмендә урамдагы колонкалардан су алу;

8) колонкаларны сүтү;

9) тротуарлардан һәм юл катламының улаклы өслегеннән чүп-чар һәм башка пычракны яңгыр сулары коеларына (рәшәткәләр өстенә) ташлау. Яңгыр сулары канализациясе челтәрен чистартканда чыккан пычрак калдыклар чистарту эшләрен башкаручы оешма тарафыннан кичекмәстән чыгарылырга тиеш;

10) урамнарда һәм квартал эчендәге территорияләрдә җир эшләре башкарганда, люкларны ватып, җир асты коммуникацияләре коеларына грунт тутыру, асфальт түшәгән вакытта, аларны асфальт белән каплау.

19 бүлек. Уен һәм спорт җиһазы

96. Сыйфатлы шәһәр мохите булдыру мәсьәләләрен хәл итү кысаларында, уен һәм спорт җиһазларын төзегәндә һәм төзекләндергәндә функциональ төрлелекне, уен һәм спорт мәйданчыкларын оештыруда, кешеләрне җәлеп итү үзәкләре буларак, комфортлы аралашу принцибы исәпкә алына.

97. Муниципаль берәмлек территориясендә уен һәм спорт җиһазлары – уен, физкультура-сәламәтләндерү җайланмалары, корылмалар һәм (яки) аларның комплекслары белән тәкъдим ителергә мөмкин. Балалар һәм яшүсмерләр өчен уен һәм спорт җиһазларын сайлаганда, аларның яшь төркемнәренең анатомик-физиологик үзенчәлекләренә туры килүен тәэмин итәргә кирәк. Уен һәм спорт җиһазлары санитария-гигиена нормалары таләпләренә туры килергә, техник эксплуатацияләү өчен уңайлы булырга, эстетик яктан үзенә тартып торырга тиеш.

98. Халыкның барлык яшь төркемнәре өчен билгеләнгән спорт җиһазлары спорт, физкультура мәйданчыкларында яки рекреация зоналары составында махсус җиһазландырылган җәяүлеләр коммуникацияләрендә (сәламәтлек сукмакларында) урнаштырыла.

20 бүлек. Яктырту һәм яктырту җиһазы

99. Шәһәр мохитенең сыйфатын тәэмин итү бурычын хәл итү кысаларында яктырту эшләре алып барганда, яктырту җиһазларын төзегәндә һәм төзекләндергәндә җәяүлеләр мохитен уңайлы оештыру принциплары, шул исәптән уңайлы һәм куркынычсыз җәяүлеләр маршрутларын булдыру, шулай ук кешеләрне җәлеп итү урыннарында аралашу өчен уңайлы мохит булдыру исәпкә алына.

100. Проектлаганда яктырту җайланмаларының төп өч төркеменә кергән (функциональ, архитектура ягыннан яктырту, яктыртулы мәгълүмат) яктырту җайланмасының һәркайсын тәэмин итәргә кирәк:

- кулланыла торган җайланмаларның экономиялелеген һәм энергетик нәтиҗәлелеген, электр энергиясен рациональ бүлү һәм куллануны;

- яктырту җайланмалары элементларының эстетикасын, дизайнын, көндезге һәм төнге вакытта ут яктысын кабул итү үзенчәлеген исәпкә алып, материалларның һәм эшләнмәләрнең сыйфатын;

- җайланмаларның төрле режимда хезмәт күрсәтү һәм идарә итү өчен уңайлылыгын.

101. Функциональ яктырту (алга таба – ФЯ) транспорт һәм җәяүлеләр зоналарында юл өлешләрен һәм киңлекләрне стационар яктырту җайланмалары белән гамәлгә ашырыла. ФЯ җайланмалары гадәти, югары мачталы, парапет, газон һәм эчкә кертелеп төзелгән җайланмаларга бүленә.

102. Гадәти җайланмаларда яктырткычларны баганаларга, фасадларга (бра, плафоннар) урнаштырырга киңәш ителә. Аларны транспорт һәм җәяүлеләр зоналарында аеруча киң куллану зарур.

103. Югары мачталы җайланмалар киң пространстволарны, транспорт төеннәрен һәм магистральләрне, ачык паркингларны яктырту өчен кулланыла.

104. Парапет җайланмаларында яктырткычлар юл үткәргечләрнең, күперләрнең, эстакадаларның, пандусларның, транспорт төеннәренең, шулай ук тротуарларның һәм мәйданчыкларның йөрү өлешен киртәләүче парапетка сынык сызык ясап яки пунктир белән көйләнә.

105. Газон яктырткычлар, гадәттә, газоннарны, чәчәклекләрне, җәяүле юлларын һәм мәйданчыкларны яктырту өчен хезмәт итә. Алар җәмәгать урыннары һәм рекреация объектлары территорияләрендә минималь вандаллык зоналарында урнаштырылырга мөмкин.

106. Баскычларда, терәк стеналарда, коймаларда, биналар һәм корылмаларның цокольләрендә, кече архитектура формаларында урнаштырылган яктырткычларны җәмәгать билгеләнешендәге территорияләрнең җәяүле зоналарын яктырту өчен файдаланырга кирәк.

107. Архитектура ягыннан яктырту (алга таба – АЯ) кичке вакытта сәнгатьчә визуаль мохит формалаштыру, архитектура, тарих һәм мәдәният, инженер һәм монументаль сәнгать һәйкәлләрен, КАФ, доминантлы һәм истәлекле объектларны, ландшафт композицияләрен яктырту, яктылык ансамбльләре төзү өчен кулланыла. Ул объектларны стационар яки вакытлыча яктырту җайланмалары белән, нигездә, фасад өлешләрен тышкы яктырту белән башкарыла.

108. АЯның вакытлы җайланмаларына түбәндәге бәйрәм иллюминациясе керә: яктылык гирляндалары, челтәрләр, контур буенча яктырту, яктылык-график элементлары, кыздыру лампалары, яктылык диодлар, яктылык үткәргечләр

кулланып, панно һәм күләмле композицияләр, яктылык проекцияләре, лазерлы рәсемнәр һәм б.ш.

109. Архитектура ягыннан яктырту максатларында шулай ук ФЯ җайланмалары бииалар һәм корылмалар фасадларын, яшел үсентеләр, иллюминация, яктылык белән бирелүче мәгълүмат һәм реклама (элементлары урам яктыркычларына беркетелгән булса) прожекторларын монтажлау кулланыла.

110. Яктыртулы мәгълүмат (алга таба – ЯМ), шул исәптән, яктыртулы реклама җәяүлеләрне һәм автотранспорт йөртүчеләрне пространствода дөрес юнәлештә хәрәкәт итүен, шул исәптән, яктылык ансамбленең гамәлдәге юл хәрәкәте кагыйдәләренә каршы килми торган гармониясен исәпкә алып, яктылык композициясе бурычларын хәл итүгә юнәлдерерә.

111. ФЯ һәм АЯ стационар җайланмаларында энергиянең нәтиҗәлелеген бирүче яктылык чыганаклары, нәтиҗәле яктырту приборлары һәм системалары, дизайн һәм эксплуатация характеристикалары буенча сыйфатлы эшләнмәләр һәм материаллар: тирәкләр, кронштейннар, саклагыч рәшәткәләр, экраннар һәм гамәлдәге милли стандартлар таләпләренә җавап бирә торган конструктив элементлар кулланыла.

112. ФЯ җайланмаларында яктылык чыганакларын таләпләрне, ориентацияне яхшырту, күрү өчен уңайлы шартлар булдыруны, кирәк булган очракта, төсле утлар белән зоналаштыруны исәпкә алып сайларга кирәк.

113. АЯ һәм ЯМ җайланмаларында барлыкка килгән яктылык һәм төсләр адаптациясе, торак пунктның аерым пространствосында яки яктылык ансамблендә барлык төркем яктырту (аеруча хроматик яктырту) җайланмаларының эшчәнлеге нәтиҗәсендә гомуми карау эффектын исәпкә алып, ак һәм төсле яктылык чыганаклары кулланыла.

114. Транспорт һәм җәяүлеләр зоналарындагы ФЯ җайланмаларында яктылыкның түбән ярымсферасында турыдан-туры, таркатып яки чагылдырып тапшыручы яктылык приборлары кулланыла.

## 21 бүлек. Реклама конструкцияләре һәм тышкы мәгълүмат чаралары

115. Реклама конструкцияләрен, мәгълүмат конструкцияләрен (алга таба – элмә такталарын) урнаштыру, шулай ук башка график элементларны урнаштыру 2006 елның 13 мартындагы «Реклама турында» 38-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турындагы Нигезнамәгә туры китереп гамәлгә ашырыла.

116. Биналарның фасадларында тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру вариантлары Башкарма комитет карары белән раслана.

117. Реклама конструкцияләре төзек инженер-техник хәлдә булырга, рөхсәт бирү һәм проект документларына туры килергә, эстетикалы, чиста булырга, аның өслегендә чит язулар, рәсемнәр, игъланнар, плакатлар, башка мәгълүмати-басма продукция һәм аларның өлешләре булмаска тиеш. Реклама конструкцияләрендәге сурәт тулы һәм бозылмаган булырга тиеш.

118. Реклама сурәте булмаса, биналарда, корылмаларда урнашкан щитлы реклама конструкцияләренең өслеге, шулай ук аерым торучы реклама

конструкцияләренең өслеге якты төсләргә буялган щитлар белән ябыла яки якты төстәге материал белән тышлана.

119. Реклама конструкцияләренең металлдан эшләнгән элементлары буялган булырга, тутыккан урыннары булмаска тиеш. Реклама конструкцияләренең таш, бетон, агачтан эшләнгән элементлары буялган булырга тиеш (декоратив бизәүдә таш яки агачның табигый төсләрен кулланудан тыш). Реклама конструкцияләре, зарурлыктан чыгып, иң кимендә елга бер тапкыр, 1 майга кадәр буяла.

120. Тыела:

1) зыян күргән реклама конструкцияләрен (сурәтләрнең, язуларның һәм б.ш. бозылуы) ике көннән артык эксплуатацияләү;

2) механик зыян күргән реклама конструкцияләрен (конструкциянең деформацияләнүе, щитка зыян килү һ.б.) ике тәүлектән артык эксплуатацияләү;

3) күчереп йөртә торган щитлы реклама конструкцияләре (штендерлар) урнаштыру.

121. Реклама продукциясенең барлык төрләрен яктырту баганаларында һәм элемтә челтәрендә милек хуҗасы белән килештермичә генә урнаштыру, әгәр аны башка субьектлар белән килештерү гамәлдәге законнар яки килешү белән каралмаган булса, тыела.

122. Газеталар, плакатлар, афишалар, игъланнар, реклама проспектлары һәм башка мәгълүмати-басма продукцияне бары тик махсус урнаштырылган щитларга, стендларга яки тумбаларга гына беркетү рөхсәт ителә. Мәгълүмати-басма продукцияне әлеге максатлар өчен билгеләнмәгән конструкцияләргә урнаштыру тыела.

22 бүлек. Капиталь һәм стационар булмаган корылмалар

123. Җиңел конструкцияләрдән эшләнгән, тирән фундамент һәм җир асты корылмаларын күздә тотмаган капиталь һәм стационар булмаган корылмалар (ваклап сату, көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм туклану объектлары, тукталыш павильоннары, җир өсте бәдрәф кабиналары, бокс, гаражлар, башка төр объектлар) төзегәндә дизайнның архитектура-сәнгать таләпләренә һәм торак пункты мохитенең характерына туры килгән, озак вакыт эксплуатацияләүгә исәпләнгән бизәкләү материаллары кулланыла. Витриналарны пыяла белән каплаганда кыйпылчыкка кисәкләнми, бәрүгә каршы тора торган материаллар, куркынычсыз, ныклы һәм күп катлы пленка белән капланган, поликарбонат пыяла кулланыла.

124. Капиталь һәм стационар булмаган корылмаларны төзегәндә һәм төзекләндергәндә шәһәр мохитенең сыйфатын тәэмин итү бурычларын хәл итү кысаларында функциональ төрлелекне, уңайлы җәяүлеләр тирәлеген, территорияне төрле сервислар белән тәэмин итү өлешендә аралашу өчен уңайлы мохит оештыру принципларын исәпкә алырга кирәк.

125. Капиталь һәм стационар булмаган корылмаларны муниципаль берәмлек территорияләрендә автомобиль һәм җәяүлеләр хәрәкәтенә комачауламаслык итеп урнаштырырга кирәк. Ваклап сату, көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм туклану предприятиеләре корылмаларын Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә урнаштырырга тәкъдим ителә.

23 бүлек. Биналар һәм корылмаларны җиһазлау һәм рәсмиләштерү

126. Бина һәм корылма фасадларының тышкы кыяфәтенә аларның төсе, фасадның конструктив элементлары, биналарның (корылмаларның) фасадлары һәм мәгълүмат элементларын урнаштыру урыннары, реклама конструкцияләре, өстәмә җиһазлар, аларның тибы, төре һәм зурлыгы керә.

127. Бина (корылма) милекчеләре, хуҗалары һәм биналарны (корылмаларны) карап тоту буенча бурычлар йөкләнгән башка затлар фасадларны тиешле хәлдә тотарга, гамәлдәге законнарда биналарны, төзелешләрне һәм корылмаларны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрендә һәм нормаларында, әлеге Кагыйдәләрдә каралган таләпләрне үтәргә тиеш.

128. Фасадларның тиешенчә торышын тәэмин итү максатларында түбәндәгеләр тыела:

1) биналарның (корылмаларның) фасадларына зыян салу, бозу, архитектура детальләрен бозу;

2) бу максатлар өчен билгеләнмәгән урыннарга, корылмалар фасадларында рөхсәтсез газеталар, плакатлар, афишалар, игъланнар, реклама проспектлары һәм башка мәгълүмати-басма продукция беркетү;

3) Башкарма комитет тарафыннан бирелүче мәгълүмат элементларын һәм биналарның (корылмаларның) фасадларын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт алмыйча бина (корылмалар) фасадларында, биналарның (корылмаларның) түбәләрендә мәгълүмати элементлар һәм биналарның (корылмаларның) фасад җайланмаларын урнаштыру.

129. Бина (корылма) фасадыннан рөхсәтсез язылган язуларны бетерү, беркетелгән мәгълүмати-басма продукцияне кубару, биналарның (корылмаларның) фасадларының мәгълүмат элементларын һәм җайланмаларын алу эшләрен оештыру биналарның (корылмаларның) хуҗаларына, хокукка ия булучы башкаларга, шулай ук биналарны (корылмаларны) карап тоту буенча вазыйфаи җаваплы затларга йөкләнә.

24 бүлек. Капиталь төзелеш элементлары

130. Капиталь төзелеш объектлары номерлар, күрсәткечләр һәм йорт билгеләре белән җиһазландырылырга тиеш.

131.Торак биналар подъезд номерлары күрсәткечләре белән җиһазландырылырга тиеш. Һәр подъезд янында әлеге подъезддагы фатир номерлары күрсәткече булырга тиеш.

132. Капиталь төзелеш объектларына кергәндә каты өслекле мәйданчыклар оештыруны күз алдында тотарга кирәк, эскәмияләр урнаштыру һәм яшелләндерүнең төрле төрләрен кулланырга мөмкин.

133. Торак һәм иҗтимагый билгеләнештәге капиталь төзелеш объектларында кондиционерлар урнаштыру аларның бина элементларына зыянлы йогынтысы булмау шарты белән башкарылырга тиеш. Кондиционерларның тышкы блокларын кондиционер эшләгән вакытта хасил булган конденсат козырекларга, тәрәзәләргә тимәслек итеп урнаштыру шарт.

134. Өстәмә җиһазлар урнаштыру Башкарма комитет яки аның вәкаләтле органы тарафыннан бирелгән архитектура йөкләмәсе нигезендә башкарыла.

135. Милекчеләр яки аларның вәкаләтле затлары, арендаторлар һәм капиталь төзелеш объектларын кулланучылар түбәндәгеләрне эшләргә бурычлы:

1) үзгәртеп планлаштырганда һәм капиталь ремонт үткәргәндә биналар һәм корылмаларның гамәлдә булган архитектура йөзен сакларга;

2) козыреклар, элмәләр, фасадта өстәмә җиһазлар урнаштыру эшләрен башкарганда капиталь төзелеш объектларының фасадларына зыян китермәскә;

3) кондиционерлар һәм антенналарның тышкы блокларын, шулай ук аларның архитектура өслекләренә зыян китерергә мөмкин булган тоташтыру элементларын архитектура детальләренә, декор элементларында, кыйммәтле архитектуралы өслекләрдә урнаштырмаска.

136. Фасадны, капиталь төзелеш объектларының түбәсен капиталь ремонтлау яки капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү вакытында:

1) аерым фасад өслегендә тәрәзәләрне, балкон һәм лоджияләрне, балкон стеналарын, яңа архитектура детальләренең формасын һәм тышкы кыяфәтен, керү урыннары өстендәге козырекларның түбәсен, су чыгару системасының бертөрле сурәттә, төстә булуы һәм бертөрле материалдан эшләнүе кирәк;

2) торак пунктның төп (магистраль) урамнарына чыгучы биналар һәм корылмалар фасадларындагы төзелеш басмаларын саклагыч сетка белән әйләндереп алырга кирәк, сеткада төзелеш компаниясе логотибын яисә фасадның перспектив кыяфәтен сурәтләү рөхсәт ителә;

3) төзелеш басмаларын сүтеп алганнан соң төзекләндерү эшләрен башкарырга кирәк;

4) төзекләндерү һәм яшеләндерү объектларының сакланышын тәэмин итәргә кирәк.

137. Тышлыкның, штукатурканың, фактура һәм буяу катламнарының урыны белән бозылуы, штукатуркада ярыклар хасил булу, тышлыкны, кирпеч һәм кечкенә блокларны тоташтыручы җөйләрдәге измәнең төсе ямьсезләнү, җыелма корылмалардагы герметизациянең зарарлануы, стеналарның алга чыгып торучы өлешендәге металл катламнарының тузуы яки зарарлануы, су чыгаручы торбаларның тузуы, аларда юеш һәм тутык таплар хасил булу, өслекнең гомуми, шул исәптән, графити белән пычрануы, парапетларның һәм башкаларның җимерелүе кичекмәстән төзәтелергә тиеш. Юридик яки физик затлар милкендә, хуҗалык алып бару яисә юридик затларның оператив идарәсендә торак булмаган аерым биналар булган очракта, андый затларга биналарның фасадларын ремонтлауда милек мәйданнарына пропорциональ рәвештә өлешләп катнашу йөкләтелә.

138. Фасадларда урнаштырылган мәгълүмати элмәләр, истәлекле такталар чиста һәм төзек хәлдә булырга тиеш.

139. Керү урыннары, цокольләр, витриналар чиста һәм төзек хәлдә булырга тиеш.

140. Йорт билгеләре чиста булырга тиеш.

141. Подъезд козыреклары, шулай ук түбә пычрактан, агач-куак һәм чүп үләннәреннән чистартылырга тиеш.

142. Кышкы чорда түбәне кардан һәм боздан вакытында чистартып тору оештырыла. Түбәләрдәге карны (бозны) тротуарларга төшерү бары тик тәүлекнең якты вакытында һәм урам якка авыш түбә өстеннән генә рөхсәт ителә. Түбәнең калган өлешеннән, шулай ук яссы түбәдән карны ишегалды территорияләренә ташларга кирәк. Кар ташлар алдыннан, транспорт чаралары хәрәкәте иминлеген һәм җәяүлеләр үтүен тәэмин итүче чикләү чаралары урнаштырып, түбәне кардан чистарту вакытына саклык чаралары күрергә кирәк.

143. Биналарның (торак фондыннан тыш) түбәсеннән ташланган карны (бозны) 24 сәгать эчендә чыгарырга кирәк. Түбәләрне кардан чистартканда агачларның, куакларның, электр яктырту линияләренең, растяжкаларның, мәгълүмат урнаштыру чараларының, юл билгеләренең, элемтә линияләренең һәм башкаларның тулы сакланышын тәэмин итүче чаралар күрелергә тиеш.

25 бүлек. Җир эшләрен башкару

144. Җир эшләрен оештыру һәм башкару, шәһәр территориясен төзекләндерү эшләрен оештыру һәм үткәрү, җир эшләре (алга таба – ордер) башкаруны рәсмиләштерү һәм рөхсәт алу, техник шартларны һәм яңгыр суларын үткәреп җибәрү проектын килештерү, төзекләндерү объектын вакытлыча ябу өчен рөхсәт яки килешү төзү һәм алу Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

145. Җир казу, юл өслеге салу, юл катламын ачу (җир асты коммуникацияләрен урнаштыру, реконструкцияләү һәм ремонтлау, субай һәм шпунт кагу, грунт планировкасы, бораулау эшләре) белән бәйле эшләрне Ордер комиссиясе биргән ордерлар булганда гына башкарырга кирәк.

146. Челтәр хуҗаларына авария эшләрен Ордер комиссиясенә телефонограмма яки хәбәр итү юлы белән белдереп һәм авария ордерын өч көнгә рәсмиләштереп башларга кирәк. Эш вакытын озынайтырга кирәк булса, Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә даими ордер ачыла.

147. Җир казу эшләре башкару урыннары җитештерүче оешманың исемен һәм телефон номерлары язылган, сигнал утлары, әйләнгеч һәм җәяүлеләр кичүе күрсәткечләре булган яктылык кайтаручы тоташ коймалар, сигналлы су салу барьерлары, ПВХ челтәре яки челтәрле коймалар белән уратып алынган булырга тиеш, кирәк булганда, кимендә 1 метр киңлектәге, ике яклап 1.1 м култыксалы, аскы яктан 0,15 м биеклектә тоташ өслектәге һәм 0,5 м биеклектә өстәмә киртәләүле планкалы күперләр һәм трап белән тәэмин ителгән булырга тиеш.

148. Җир эшләре башкарган вакытта:

1) агач һәм куаклыкларны 2 м биеклектәге тоташ койма белән тотарга, койманы агач кәүсәсеннән 0,5 м ераклыкта өчпочмаклап урнаштырырга, өчпочмаклы коймадан 0,5 м радиуста агач өслек ясарга, агач һәм куакларның кәүсәләрен саклау өчен бәйләргә кирәк;

2) агач һәм куакларның тамыр системасына зыян китермәскә кирәк;

3) агач һәм куакларның туфрак һәм төзелеш калдыклары белән күмелүенә юл куймаска кирәк;

4) туфракның үсемлекле өлешен 0,2 - 0,3 м итеп алырга, аны соңыннан территорияне төзекләндергәндә, чәчәклекләр һәм газоннар ясаганда куллану өчен

Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән махсус урыннарга чыгарырга; туфракның үсемлекле өлешен аскы, үсемлексез катламнары белән кушылудан, пычранудан, су белән юылудан һәм җилләүдән сакларга кирәк;

5) туфракны Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән урыннарга чыгарырга кирәк;

6) күчереп утыртырга яраклы агачлар һәм куакларны казып алырга һәм әлеге яисә башка обьектны яшелләндергәндә кулланырга кирәк;

7) яшел үсентеләрне су басу куркынычы булса, дренаж кулланырга кирәк;

8) юлларны, мәйданнарны, йорт яны территорияләрен, тротуарларны асфальтлаганда яки аларга таш түшәгәндә, агач тирәли диаметры 1,5 метрдан да ким булмаган буш урын (кәүсә янындагы чокырлар) калдырырга кирәк;

9) төзелеш материалларын агачтан 2,5 м һәм куаклардан 1,5 м ераклыкта итеп урнаштырырга, янучан материалларны агач һәм куаклыкларга 10 м дан да якынрак итеп урнаштырмаска кирәк;

10) күтәрткеч краннар һәм башка төзелеш техникасы өчен керү юлларын һәм урнаштыру урыннарын яшел үсентеләргә зыян китермәслек итеп салырга кирәк.

149. Юл өслекләре, тротуарлар, газоннар һәм башка казылган участоклар, рөхсәт кәгазендә күрсәтелгән срокларда, тулысынча һәм сыйфатын киметмичә төзекләндерелергә тиеш.

150. Юл йөрү урыннарында (магистральләрдә), урамнарда, мәйданнарда төзелеш эшләре җәяүлеләр һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүне исәпкә алып оештырылырга тиеш. Тротуарларда, җәяүлеләр сукмакларында эшләр башкарганда, кешеләр өчен уңайлы һәм куркынычсыз шартлар тәэмин ителергә тиеш.

151. Җир эшләре башкарганда урамнарда, тротуарларда өлешчә яки тулысынча хәрәкәтне ябу Башкарма комитет һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсенең ЮХИДИ бүлеге белән килешү нигезендә башкарыла.

152. Тротуарлар һәм җәяүлеләр юллары траншеялар белән кисешкән урында, кичүнең тулы киңлегенә җәяүлеләр өчен күперчекләр һәм ике яктан 1 метрдан да ким булмаган биеклектә киртә куелырга тиеш.

153. Хәрәкәт иминлеген һәм билгеләнгән таләпләрне үтәү өчен эшләр башкаруга закон нигезендә рөхсәт бирелгән зат җаваплы.

154. Асфальт-бетон катламнарын ачу участок чикләре буенча өслекне кискәннән соң башкарыла. Юлның кеше йөри торган өлешенә һәм якындагы территориядә асфальт-бетон катламын (ватыкларын) кую тыела. Аннан соң җир эшләрен механикалаштырылган ысул белән юлларны саклый торган туфрак һәм юл өслекләрен бозмыйча, җир эшләрен башкару проекты нигезендә башкарырга мөмкин.

155. Җир эшләрен башкаручы оешма, юридик яки физик зат эшне үткәрү урынын, оешма исемен, телефон номерын һәм эшне үтәүченең фамилиясен күрсәтеп, бөтен периметр буенча киртә белән әйләндереп ала. Кичке һәм төнге вакытта урам, мәйдан, юл йөрү урыннарында урнаштырылган киртәләр өстәмә рәвештә яктыртылырга тиеш.

156. Траншея һәм котлованнарны күмү катлам-катлам итеп башкарыла, һәр катламның калынлыгы 0,2 метрдан артмаска, тыгызлап тутырылырга тиеш, кышкы

чорда күмү өчен ком һәм туфрак кулланыла, тыгызлану коэффициенты 1,0 метр тирәнлектән дә ким булмаска тиеш.

157. Машиналар юлында траншеяларны катламлап тутыралар, катламнарны тыгызлау кул яки механикалаштырылган ысул белән һәм елның җылы вакытында су сибү юлы белән башкарыла.

158. Җир эшләрен башкаручы оешма җир казу урыннарында бозылган газоннар, яшел үсентеләр, асфальт-бетон катламны һәм бордюр ташын тулысынча һәм сыйфатлы итеп яңартырга тиеш.

159. Урам траншеялар белән кисешкәндә, юлның асфальт-бетон өслеге карталар белән төзекләндерелә. Алар траншеяның һәр ягына биш метрдан да ким булмаган, тротуарда – өч метрдан да ким булмаган үлчәмдә башкарыла, юлда бордюр ташының биеклеге 15 сантиметрдан кимрәк булмаска, тротуарда – асфальт белән бертигез булырга тиеш.

160. Казылган җир тирәнлеге 1 метрдан артмаган очракта, асфальт-бетон өслеген җәю, эшләр тәмамланып, траншеяны күмгәннән соң башкарыла. Чокырлар тирән булганда яки эшләрне кыш көне башкарганда, траншеяны күмгәннән соң, автотранспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәте өчен асфальт-бетон өслек урынына юл плитәләреннән яки башка материалдан (битум өслекле кирпеч, таш һ.б.) вакытлыча өслек җәелә, даими өслек рөхсәт кәгазендә билгеләнгән вакытта җәелә.

161. Асфальт-бетон өслеген торгызу өчен урамнарда, юлларда, тротуарларда, мәйданнарда җир эшләре башкаручы оешмалар һәм физик затлар җаваплы.

162. Коммуникацияләр салган вакытта тротуарларның, җәяүле юлларының һәм юлларның асфальт-бетон өслеге бозылган очракта, өслек тротуар һәм юлларның тулы киңлегендә һәм бордюр ташларын урнаштырып яңартыла.

163. Казу эшләре юл киңлегенең 1/3 өлешеннән артып киткән, юлның хәрәкәт итү өлешендә траншея казылып, аның озынлыгы әлеге урамның, юлның, мәйданның 1/50 озынлыгыннан артып киткән очракта, юлның, урамнарның, мәйданнарның өслеге шул ук тәртиптә яңартыла.

164. Җир эшләре башкару урынында асфальт-бетон катламы сыйфатсыз җәелгән очракта яки ике ел дәвамында аның иңүе күзәтелсә, аны яңадан җәюне җирне казыган оешма башкара.

165. Казу эшләре урыннарында һәм территория янәшәсендә яңгыр һәм эрегән кар суларын агызуны җир эшләре алып баручы оешма тәэмин итә. Коеларны, яңгыр сулары агып төшүче кое, рәшәткә һәм улакларны саклау өчен агач щитлар һәм тартмалар кулланылырга тиеш.

166. Коммуникацияләр белән кисешкән урыннарда траншея күмү әлеге җир асты коммуникацияләрен эксплутацияләүче оешма вәкилләре катнашында башкарыла.

167. Җир эшләре өчен җаваплы зат траншея һәм котлованнарны күмә башлау турында тиешле оешмаларга вакытында хәбәр итәргә тиеш.

168. Җир асты корылмалары (торбаүткәргечләр, коелар, кабельләр, фундаментлар һ.б.) янында җир эшләре башкарганда, эш проекты белән каралганнан кимрәк ераклыкта экскаватор куллану тыела. Мондый очракта кул хезмәте файдаланыла. Туң җирдә эшләр башкарганда, газүткәргеч торбалар, электр кабельләреннән 5 метрдан да якынрак араларда, башка җир асты коммуникацияләре һәм объектларыннан 3 метрдан да якынрак араларда чөйсыман

җайланмалар куллану тыела. Мондый җайланмаларны торак йортлар янында да куллану тыела.

169. Күрсәтелгән барлык эшләр дә җир эшләрен башкаручы предприятие көче һәм хисабына башкарыла.

170. Җир эшләре башкарганда түбәндәгеләр тыела:

1) Башкарма комитет һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсе ЮХИДИ бүлеге белән килештермичә юлларда җир эшләре башкару;

2) проектта күрсәтелмәгән җир асты корылмалары, коммуникацияләр ачыкланган очракта, алар эшләр башкаруга комачауламаса да, кызыксынган оешма белән килештермичә генә җир эшләрен башкару;

3) расланган проектта каралмаган очракта, җир асты корылмаларын (әлеге корылмалар эшләр башкаруга комачауламаса да) хезмәт күрсәтүче оешма һәм муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы белән килештермичә бер урыннан икенче урынга күчерү;

4) урамның тирә-ягын пычрату һәм яңгыр сулары канализациясенә чүп тутыру, суүткәргеч торбалар, кюветлар һәм газоннарга туфрак ташлау;

5) бозлавык хасил булмасын өчен траншея, котлован, коелардан юлга, тротуарларга су чыгару. Яңгыр сулары канализациясенең хуҗасы белән килешенеп, су агымы әлеге участокта булган яңгыр канализациясенә юнәлдерелергә тиеш;

6) Башкарма комитет рөхсәтеннән башка агач, куаклар кисү, аларның тамырларын җир өстенә чыгару;

7) авария эшләреннән тыш, яшел утыртмаларны казып алу;

8) геодезия хезмәте тарафыннан контроль төшерү ясамыйча, кабель, җир асты коммуникацияләренең өскә чыкмаган торбаларын урнаштыру өчен салынган траншеяларны күмү;

9) кое һәм камера люкларының капкачларын, яңгыр сулары коеларының рәшәткәләрен, юл өслеге улакларын, яшел утыртмаларны, шулай ук газон материаллары һәм конструкцияләрен, гамәлдәге җир асты коммуникацияләре трассаларын, газүткәргечләрнең саклау зоналарын, җылылык трассаларын, электр тапшыру линияләрен һәм элемтә линияләрен туфрак белән күмү;

10) котлован, траншея, юл катламындагы грунтны төзелеш мәйданы чикләреннән читкә чыгару.

171. Урам һәм юллардагы карау һәм яңгыр суы коелары юл өслеге белән бер үк тигезлектә яңартылырга тиеш.

172. Траншея һәм котлованнарны күмү җир эшләре башкаруга рөхсәттә күрсәтелгән срокта, рөхсәт биргән орган вәкиле катнашында акт төзеп башкарылырга тиеш.

173. Саклау зоналары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрендә үткәрелә торган эшләр Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә башкарыла.

## III кисәк. Төзекләндерү объектларын карап тоту һәм эксплуатацияләү тәртибе

26 бүлек. Төзекләндерү объектларын карап тоту

174. Төзекләндерү объектларын ремонтлау (агымдагы, капиталь) эшләре түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) кирәк булганда, юл өслекләрен, тротуарларны һәм аларның конструктив элементларын төзәтү һәм алыштыру;

2) кирәк булганда, МАФ һәм аларның аерым элементларын урнаштыру, алыштыру, төзәтү;

3) санитария кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә, киләчәктә алыштыру мөмкинлеген исәпкә алып, урналар, җиһазлар һәм контейнер мәйданчыклары урнаштыру;

4) кирәк булганда, яшел үсентеләрне карау буенча агымдагы эшләрне башкару;

5) җимерелгән коймаларны һәм мәйданчыкларның җиһазларын ремонтлау һәм яңарту;

6) кирәк булганда, әмма иң кимендә ике елга бер тапкыр тышкы яктырту объектларын яңарту, яктырту баганаларын буяу;

7) корыган, начарланган һәм декоратив кыяфәтен югалткан яшел утыртмаларны кисү, агач һәм куаклар утырту, газоннар чәчү, үсемлекләрне санитар кисү, кирәкмәгән утыртмаларны казып алу, утыртмаларны кисеп, алардан читәннәр формалаштыру; кирәк булганда, зыян күргән урыннарны дәвалау.

175. Төзекләндерү (агымдагы, капиталь) буенча эш төрләрен билгеләү төзекләндерү өлкәсендә гамәлдә булган норматив документлар нигезендә башкарыла.

176. Төзекләндерү объектларын карап тоту түбәндәге эшләрне үз эченә ала:

1) төзексезлек, зыян килү һәм төзекләндерү объектларына һәм элементларына, аларны карап торудагы башка таләпләрнең бозылу очракларын ачыклау максатыннан, билгеләнгән территориядә урнашкан барлык төзекләндерү элементларын һәм объектларын көн саен карап чыгу. Күрсәтелгән хокук бозулар ачыкланган очракта, алар 14 календарь көн эчендә төзәтелергә тиеш (әлеге Кагыйдәләр белән башка сроклар билгеләнгән эш төрләреннән тыш);

2) яшел утыртмаларны карау буенча чаралар (су сибү, газоннарны чабу һәм башкалар);

3) яңгыр һәм грунт сулары өчен билгеләнгән чокырларны, торбаларны, дренажларны калдыклардан һәм чүп-чардан чистарту – яз көне бер тапкыр һәм алга таба, чүпләнгән саен;

4) КАФны һәм төзекләндерү элементларын чистарту, буяу – кирәк булганда һәм әлеге объектларның техник һәм эстетик торышын исәпкә алып, әмма кимендә елга бер тапкыр;

5) урналарны бушатуны чүп җыелган саен (аларның тулуын көтмичә) башкарырга кирәк, аларны юу һәм дезинфекцияләү айга бер тапкыр (елның җылы вакытында), буяу – елга иң кимендә бер тапкыр, металл урналарны – кимендә елына ике тапкыр (яз һәм көз көне) башкарырга кирәк;

6) территорияне көн саен җыештыру (себерү, чүп-чар, кар, боз катламыннан чистарту, төзекләндерү объектларын чисталыкта тоту өчен башка технологик операцияләр уздыру);

7) расланган графиклар нигезендә даими планлы система буенча калдыкларны җыю һәм чыгару.

177. Йорт яны һәм ишегалды территорияләрен карап тоту һәм җыештыру эшләре торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормалары белән билгеләнгән күләмдә һәм вакыт аралыгында үткәрелә.

178. Яшел үсентеләрне кисүдән (аларның зыян күрүеннән) хасил булган калдыкларны җыю әлеге яшел үсентеләрне кискән оешмалар тарафыннан башкарыла.

179. Яшел утыртмаларны кисүдән (аларның зыян күрүеннән) хасил булган калдыкларны төп урамнар һәм магистральләр территориясеннән чыгару эш көне барышында, ә икенчел әһәмияттәге урамнардан һәм ишегалды территорияләреннән чыгару тәүлек дәвамында башкарыла. Кисүдән соң калган агач төпләре районның төп урамнарында һәм магистральләрендә бер тәүлек эчендә, икенче дәрәҗәдәге урамнарда һәм ишегалларында өч тәүлек эчендә юк ителә. Ауган агачлар территория милекчесе тарафыннан юлның хәрәкәт итү өлешеннән, тротуарлардан, электр үткәргечләрдән, торак һәм җитештерү биналарының фасадларыннан – кичекмәстән, башка территорияләрдән – 8 сәгать эчендә чыгарыла.

180. Контейнер мәйданчыкларын карап тоту санитария нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә башкарылырга тиеш.

181. Кешеләр күпләп җыела торган урыннар (базар территорияләренә килү юллары, сәүдә зоналары һ.б.) чиста булырга тиеш.

27 бүлек. Муниципаль берәмлекнең гомуми файдаланудагы территорияләрендә көзге-кышкы чорда чистарту эшләрен оештыру һәм башкару

182. Территорияне көзге-кышкы чорда җыештыруны 16 октябрьдән 14 апрельгә кадәр башкарырга, чүп-чар, коелган яфраклар җыештыру һәм түгүне, кар һәм боз, пычрактан арындыруны, урамнарны хлорид катнашмалары кушылган ком белән эшкәртүне күздә тотарга. Кыш уртача климат үзенчәлекләреннән үзгә килгән очракта, кышкы җыештыру эшләрен башлау һәм тәмамлау вакыты үзгәрергә мөмкин.

183. Җыештыру техникасын кышкы чорга әзерләү чаралары Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән срокларда үткәрелә.

184. Автотранспорт, халык хәрәкәтенә комачаулык тудырмау һәм 24 сәгать эчендә чыгару шарты белән, яңа яуган карны өемнәргә өю барлык урамнарда, мәйданнарда, яр буйларында, бульварларда һәм скверларда рөхсәт ителә.

185. Урамның киңлегенә һәм хәрәкәт характерына карап, анда кар өемнәрен юлның ике ягы буенча яисә берьяклап, җәяүлеләр һәм автомобиль хәрәкәте өчен юл калдырып, тротуар буйлап өяргә кирәк.

186. Ком сибүне һәм бозлавыкка каршы махсус материаллар белән эшкәртүне кар яву яки бозлану барлыкка килү белән башларга кирәк. Бозлавык вакытында, беренче чиратта, төшү, күтәрелү урыннары, юл киселешләре, җәмәгать транспорты тукталышлары, җәяүлеләр кичүе эшкәртелә.

187. Интенсив җәяүлеләр хәрәкәте булган зоналарда кеше һәм хайваннар сәламәтлегенә, үсемлекләргә, аяк киеменә зыян китерә торган химик реагентлар куллану тыела (яисә минималь күләмдә рөхсәт ителә). Тротуарларга хлоридсыз коры ком сибәргә кирәк.

188. Барлык тротуарлар, ишегаллары, урамнарның машиналар йөри торган өлеше, улаклар, яр буйлары, базар мәйданнары һәм асфальт өслекле башка участокларны кардан чистарту, боз вату һәм ком сибү эшләрен 8:00 сәгатькә кадәр башкарырга кирәк.

189. Урамнар, мәйданнар, күперләр, плотиналар, скверлар һәм бульварларны кар һәм боздан чистарту эшләренә кар ява башлауга ук керешергә, беренче чиратта, транспортның өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү өчен магистраль урамнардан, автобус трассаларыннан, күперләрдән, плотиналардан һәм юллардан башларга кирәк.

190. Вакытлыча кар өю урыннары ел саен Башкарма комитет тарафыннан Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең Яр Чаллы шәһәрендәге территориаль бүлеге белән килешү нигезендә билгеләнә.

191. Җәмәгать пассажир транспорты тукталышларыннан, җир өсте җәяүлеләр кичүеннән, күперләрдән, юл өстендәге күперләрдән, халык күпләп йөри торган урыннардан (эре сәүдә үзәкләре, базарлар һ.б.), хастаханә территориясеннән һәм башка социаль әһәмияткә ия объектлардан, юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итүче урамнардан һәм башка территорияләрдән кар чыгару кар яву туктаганнан соң 24 сәгать эчендә башкарыла.

192. Урам, юл һәм мәйданнардан кар чистарту техникасы үткәннән соң, махсус оешмалар бордюр яннарын, керү юлларын, җәяүлеләр юлларын, объектлар ягыннан һәм каршы яктан, әгәр анда башка корылмалар булмаса, чистартырга тиеш.

193. Тротуарлар, ишегалды территорияләре һәм юллары кар һәм боз катламыннан каты өслеккә кадәр чистартылырга тиеш. Бозлавык хасил булганда, бозлавыкка каршы материаллар белән эшкәртү эшләре башкарыла. Тротуарларны ишегалды территорияләрен һәм юлларны чистарту кар явып туктаганнан соң 12 сәгатьтән дә соңга калмый башкарылырга тиеш.

194. Тротуарларда, җәяүлеләр сукмакларында һәм җәмәгать пассажир транспортының утырту мәйданчыкларында кар чистарту эшләрен (механикалаштырылган себерү һәм кул белән көрәү) кар явып бетүгә үк башларга кирәк. Озаклап кар яуган вакытта, җәяүлеләрнең иминлеген тәэмин итеп, кар чистарту һәм бозлавыкка каршы материаллар белән эшкәртү циклларын кабатларга кирәк.

195. Тротуарлар һәм баскычлар яңа яуган яисә тыгызланган кардан (бозлы кардан) бөтен киңлеге белән каты өслеккә кадәр чистартылырга тиеш.

196. Кар яуганда тротуарлар һәм баскычлар, биналарга (җәмәгать урыннарына) керү мәйданчыклары һәм басмалар чистартылырга һәм бозлавыкка каршы материаллар белән эшкәртелергә тиеш.

197. Кар яву чорында торак йорт һәм ишегаллары территорияләрен җыештыру, торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормалары белән билгеләнгән вакытта һәм ешлыкта башкарыла.

198. Ишегалды территорияләреннән һәм квартал эчендәге юллардан чистартылган карны ишегалды территорияләрендә, җәяүлеләр һәм автотранспорт хәрәкәтенә комачауламаучы урыннарда туплау рөхсәт ителә. Кар өемнәренең яшел үсемлекләргә зыян китермәве шарт.

199. Кышкы вакытта бина хуҗалары һәм арендаторлары тарафыннан түбәләрне кардан, боздан һәм боз сөңгеләреннән чистартып тору оештырылырга тиеш.

200. Җәяүлеләр зоналарына чыга торган якларда биналарның түбәсен чистарту, боз катламнары барлыкка килүгә башкарылырга, куркыныч участоклар койма белән әйләндереп алынырга тиеш. Тышкы су чыга торган түбәләрне кар катламын 30 см калынлыктан арттырмыйча, даими рәвештә чистартырга кирәк.

201. Бина түбәләрендәге карны, боз катламын тротуарларга ыргытып чистарту бары тик тәүлекнең якты вакытында һәм түбәнең урамга авыш өлешеннән генә рөхсәт ителә. Түбәнең башка ягыннан, шулай ук тигез түбәләрдән карны ишек алдына ыргытырга кирәк. Карны ыргыту алдыннан, торак йортта яшәүчеләрнең һәм җәяүлеләрнең иминлеген тәэмин итү максатыннан, саклык чаралары күрү шарт. Бина түбәсеннән ташланган кар һәм боз сөңгеләрен тиз арада җыеп, урам җыештыручы оешма (килешү буенча) җыеп алсын өчен, юлның машиналар йөрү өлешенә һәм урамнарның улаклы ягына чыгару кирәк. Су торбалары бүрәнкәләренә кар, боз һәм чүп ташлау тыела. Түбәләрдән кар ташлаганда агачларның, куакларның, урам электр элемтәсе линияләренең, растяжкаларның, реклама конструкцияләренең, светофор объектларының, юл билгеләренең, элемтә линияләренең һәм башкаларның тулы сакланышын тәэмин итүче чаралар күрелергә тиеш.

28 бүлек. Муниципаль берәмлекнең гомуми файдаланудагы территорияләрендә язгы-җәйге чорда чистарту эшләрен оештыру һәм үткәрү

202. Территорияне язгы-җәйге җыештыру 15 апрельдән 15 октябрьгә кадәр башкарыла, ул урамнарны, тротуарларны, мәйданнарны юу, су сибү һәм таберү эшләреннән гыйбарәт.

203. Урам һәм мәйданнарның машиналар йөри торган өлешен тулысынча юарга кирәк.

204. Улак һәм бордюрларны юганнан соң калган ком, тузан, чүптән чистартуны 7.00 сәгатькә төгәлләү шарт.

205. Тротуарларны һәм ишегалды территорияләрен юу, яшел үсентеләргә һәм газоннарга су сибүне территориядән файдаланучы оешма һәм милек хуҗалары башкара.

206. Юл өслекләрен һәм тротуарлар юуны, шулай ук тротуарлар себерүне 23.00 сәгатьтән 7.00 сәгатькә кадәр башкарырга, ә урамнарның йөрү өлешен юешләп себерүне, кирәк булганда, 9.00 сәгатьтән 21.00 сәгатькә кадәр башкарырга кирәк.

207. Муниципаль берәмлек территориясендә автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосада, автомобиль юлларының аерым полосаларында, автозаправка пунктлары янындагы территорияләрдә һәм юл буе сервисының башка объектларында үләннәрнең биеклеге 20 см дан артмаска тиеш.

208. Ишегалды территорияләрен, ишегалды эчендәге юлларны һәм тротуарларны тузаннан һәм вак көнкүреш чүп-чарыннан чистарту механикалаштырылган ысул белән яки кулдан башкарыла, территориянең чисталыгы эш көне дәвамында тәэмин ителергә тиеш.

29 бүлек. Каты коммуналь калдыкларны чыгару

209. Калдыкларны чыгаруны бу эшчәнлек төренә лицензиясе булган махсус оешмалар башкара. Каты коммуналь калдыкларны чыгару каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау хезмәтләре күрсәтүгә килешү шартлары нигезендә башкарыла.

**IV кисәк. Комплекслы төзекләндерү проектлары, шәһәр мохитен үстерү карарларын кабул итүдә һәм тормышка ашыруда иҗтимагый катнашу формалары һәм механизмнары**

30 бүлек. Гомуми нигезләмәләр. Иҗтимагый катнашуның бурычлары, файдасы һәм формалары

210. Шәһәр халкының актив өлеше, берләшмәләр вәкилләре тормыш һәм шәһәр мохитенең сыйфатын күтәрү, шәһәр халкының әйләнә-тирә мохиттән канәгатьлеген арттыру максатында карар кабул итүгә һәм шәһәр территорияләрен төзекләндерү проектларын тормышка ашыруга җәлеп ителергә тиеш, бу эшләрдә шәһәр үсешенең барлык субъектлары фикерен исәпкә алырга кирәк.

211. Барлык кызыксынган якларның киң катнашуын, иҗтимагый мәнфәгатьләрнең, теләкләрнең һәм профессиональ экспертизаның оптималь ярашуын тәэмин итү өчен түбәндәгеләр кирәк:

1) иҗтимагый ихтыяҗны ачыклау, хәрәкәт итүче кыйммәтләрне формалаштыру һәм карап тикшерелә торган проектның максатларын билгеләү этабында иҗтимагый катнашуны максималь итү;

2) бурычларны хәл итүнең альтернатив концепцияләрен эшләүдә, шул исәптән проект семинарлары һәм ачык конкурслар механизмын файдаланып, иҗтимагый катнашу һәм профессиональ экспертизаның тәңгәл килүе;

3) әлеге территориягә һәм әлеге мәсьәләгә мөнәсәбәтле шәһәр тормышының барлык субъектларын җәлеп итү белән булдырылган вариантларны карау;

4) сайланган концепцияне эшләп бетерү өчен кабаттан белгечләргә бирү һәм ахыргы нәтиҗәне карап тикшерү, шул исәптән барлык кызыксынган субъектлар катнашында аның нәтиҗәлелеген һәм җәлеп итүчәнлеген көчәйтү.

31 бүлек. Иҗтимагый катнашуны оештыру принциплары һәм механизмнары

212. Иҗтимагый катнашуның бөтен формалары барлык кызыксынган якларның шәһәр тормышының барлык субъектларын территориянең үсеш стратегиясен гамәлгә ашыра торган проектларга тагын да тулырак кушылуларына, аларның чынлап кызыксынуларын һәм кыйммәтләрен ачыклауга, аларның шәһәрдәге теләсә кайсы үзгәрешләрен проектлауда чагылыш табуына, проектларны тормышка ашыруда максатлар һәм планнар буенча килешүгә ирешүгә, мобилизацияләүгә һәм берләшүгә юнәлдерелгән.

213. Территорияләрне төзекләндерү проектлары буенча ачык фикер алышуларны проектның бурычларын формалаштыру этабында һәм һәр проектлау этабының йомгаклары буенча оештырырга кирәк.

214. Территорияләрне төзекләндерүгә һәм үстерүгә кагылышлы барлык карарлар тиешле территориядә һәм шәһәр тормышының барлык субъектларында яшәүчеләрнең фикерләрен исәпкә алып, ачыклык һәм хәбәрдарлык шартларында кабул ителергә тиеш.

215. Халыкның һәм шәһәр тормышының башка субъектларының шәһәр мохитен төзекләндерү һәм комплекслы үстерү өлкәсендәге бурычлар һәм проектлар турында мәгълүмат алулары һәм хәбәрдарлык дәрәҗәләрен күтәрү өчен «Интернет» челтәрендә интерактив портал булдыру кирәклеге тәкъдим ителә.

216. Төп проект һәм конкурс документларын «Интернет» челтәрендә ирекле карый алуны, шулай ук төзекләндерү проектларын, иҗтимагый фикер алышудан видеоязмалар эшләүне һәм аларны махсуслаштырылган муниципаль ресурсларда урнаштыруны тәэмин итәргә кирәк. Моннан тыш, проектларның материаллары буенча ачык комментарийлар бирү һәм фикер алышу мөмкинлеген тәэмин итү тәкъдим ителә.

217. Карарлар кабул итү процессында һәм комплекслы төзекләндерү проектларын тормышка ашыруда гражданнар катнашуына ирешү өчен түбәндәге форматларда эшләү кирәк:

1) территорияне үстерү буенча максатлар һәм бурычларны берлектә билгеләү, проблемаларны һәм мохитнең потенциалларын инвентаризацияләү;

2) активлыкның, функциональ зоналарның төп төрләрен һәм сайланган территориядә аларның үзара урнашуларын билгеләү;

3) җиһазлар, капиталь булмаган объектлар, кече архитектура формалары буенча фикер алышу һәм төрләрен сайлау, аларның функциональ билгеләнешен, тиешле габаритларын, стиль чишелешен, материалларын да кертеп;

4) территорияне функциональ зоналаштыруны исәпкә алып, катламнарның төрен сайлауда консультацияләр бирү;

5) күздә тотылган яшелләндерү төрләре буенча консультацияләр;

6) күздә тотылган яктырту һәм яктырту җиһазларының төрләре буенча консультацияләр бирү;

7) проект эшләүдә катнашу, карарларны архитекторлар, проектлаучылар һәм башка профиль белгечләре белән тикшерү;

8) проект карарларын проектлау процессында катнашучылар һәм алардан файдаланачак затлар белән килештерү, җирле яшәүчеләрне (зурлар һәм балалар), эшмәкәрләрне, күрше территория милекчеләрен һәм башка кызыксынган якларны да кертеп;

9) проектны тормышка ашыру процессына иҗтимагый контрольне гамәлгә ашыру (теләсә кайсы кызыксынган як контроле өчен мөмкинлек, шулай ук эшче төркем, проектның иҗтимагый советын, яисә проектның күзәтү советын формалаштыруны да кертеп);

10) территорияне эксплуатацияләү процессына иҗтимагый контрольне гамәлгә ашыру (теләсә кайсы кызыксынган як контроле өчен мөмкинлек, шулай ук эшче төркем, проектның иҗтимагый советын, яисә территорияне эксплуатацияләүгә регуляр бәя биреп тору өчен проектның күзәтү советын формалаштыруны да кертеп).

218. Проектларны тормышка ашырганда мөмкин булган барлык төр коммуникация чаралары ярдәмендә планлаштырылган үзгәрешләр һәм әлеге процесста катнашу мөмкинлекләре турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат җиткереп торуны тәэмин итәргә кирәк:

1) проектның барышы турында мәгълүмат җыю, «онлайн» катнашуны тәэмин итү һәм иҗтимагый фикер алышулар үткәрү йомгаклары буенча фото, видео һәм хисап текстларын бастырып чыгарып, регуляр рәвештә мәгълүмат җиткереп тору буенча бурычларны хәл итү өчен интернет-ресурстан файдалану (шәһәр сайты, социаль челтәрләр яки кушымталар);

2) проектның потенциаль аудиториясенә һәм төрле яшьтәге киң даирә кешеләренә мәгълүмат җиткерә ала торган җирле массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү;

3) проектлана торган объектка турыдан-туры якын урнашкан торак йортларның подъездларындагы мәгълүмат такталарында, шулай ук объектның үзендәге махсус стендларда, кешеләр җыела торган урыннарда (җәмәгать һәм сәүдә-күңел ачу үзәкләре, мөһим урыннар һәм мәйданчыклар), проектлана торган территориянең күршесендә урнашкан яки шундагы әһәмияткә ия һәм социаль инфраструктуралы объектларның холларында (шифаханәләр, китапханәләр, спорт үзәкләре һ.б.) иҗтимагый фикер алышулар үткәрелә торган мәйданчыкларда (керү урыннары зонасында, махсус мәгълүмат стендларында) афишалар һәм игъланнар элү;

4) җирле халыкка мәгълүматны мәктәпләр һәм балалар бакчалары аша җиткерү. Шул исәптән мәктәп проектлары: рәсем конкурслары оештыру,

теләкләрне туплау, иншалар, макетлар, проектлар, укучыларның ата-аналары өчен анкеталар, чакырулар тарату;

5) очрашуда катнашучыларны шәхсән чакырулар электрон почта яки телефон аша башкарыла;

6) мәгълүматны төрле шәһәр һәм профессиональ берлекләргә җиткерүне тәэмин итү өчен социаль челтәрләрне һәм интернет-ресурсларны файдалану;

7) зур булмаган анкеталар тутыру һәм җыю өчен җайланмалар белән интерактив стендлар урнаштыру, иҗтимагый тормыш үзәкләрендә һәм кешеләр күпләп җыела торган урыннарда теләк һәм тәкъдимнәр җыюны үткәрү өчен территориянең генераль планы белән стендлар урнаштыру;

8) кешеләр күп йөри торган урыннарда, проектлау объектының үзенең территориясендә махсус мәгълүмат стендлары урнаштыру. Стендлар анкеталар, мәгълүматлар җыю һәм кире элемтәләр өчен хезмәт итәргә дә, проектлау процессының барлык этаплары һәм иҗтимагый фикер алышулар үткәрүнең йомгаклары буенча хисапларны халыкка җиткерү өчен мәйданчык булырга да мөмкин.

219. Проектларны тикшерү җәлеп итү һәм түбәндәге ысуллар ярдәмендә төркемдә эшләүнең заманча алымнарының киң җыелмасын файдаланып катнашуны тәэмин итү өчен түбәндәге интерактив форматта үтәргә тиеш: анкеталаштыру, сораштыру, интервью бирү, фокус-төркем үткәрү, кулланучыларның аерым төркемнәре белән эшләү, проект семинарлары, проект остаханәләре (воркшоплар) оештыру, иҗтимагый фикер алышулар уздыру, зурлар һәм балалар катнашында дизайн-уен үткәрү, проект остаханәләрен укучылар һәм студентлар белән оештыру, мәктәп проектлары (рәсемнәр, иншалар, теләкләр, макетлар), территорияне эксплуатацияләүгә бәя бирү.

220. Проектлауның һәр этабында әлеге конкрет ситуация өчен максималь туры килерлек механизмнарны сайларга кирәк, алар гади һәм проекттагы барлык кызыксынган затлар өчен аңлаешлы булырга тиеш.

221. Иҗтимагый фикер алышуларны үткәрү өчен кешеләргә яхшы билгеле, транспорт белән бару уңайлы булган, проектлана торган объект янәшәсендә урнашкан иҗтимагый һәм мәдәни үзәкләрне (мәдәният сарайлары, мәктәпләр, яшьләр һәм мәдәни үзәкләр) сайларга кирәк.

222. Иҗтимагый фикер алышулар проект процессында катнашучыларның барысына да нейтраль позициядә булган тәҗрибәле модератор катнашында үткәрелергә тиеш.

223. Очрашулар, проект семинарлары, воркшоплар, дизайн-уеннар һәм иҗтимагый фикер алышуларның башка теләсә кайсы форматларының йомгаклары буенча очрашу турында хисап эшләп куелган, шулай ук очрашуның үзеннән видеоязма төшерелгән булырга һәм гражданнар проектның үсеш процессын күзәтеп барсын, шулай ук комментарийлар бирсен һәм теләсә кайсы этапта процесска кереп китә алсын алсын өчен, проектның мәгълүмат ресурсларында, шулай ук муниципалитетның рәсми сайтында һәркем күрә алырлык итеп урнаштырылырга тиеш.

224. Квалификацияле катнашуны тәэмин итү өчен, проект турында, проект алды тикшерүләре нәтиҗәләре хакындагы актуаль мәгълүматны, шулай ук проектның үзен бастырып чыгару иҗтимагый фикер алышулар үткәрүгә кадәр 14 көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырылырга тиеш.

225. Төзекләндерү өлкәсендәге иҗтимагый контрольне теләсә кайсы физик һәм юридик зат гамәлгә ашырырга хокуклы, шул исәптән фото-, видеофиксация өчен техник чаралар кулланып, шулай ук «Интернет» челтәренең гомумшәһәр интерактив порталларында. Төзекләндерү өлкәсендәге иҗтимагый контроль кысаларында ачыкланган һәм теркәп куелган кимчелекләре турындагы мәгълүмат, чара күрү өчен, шәһәр башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына һәм (яки) «Интернет» челтәренең гомумшәһәр интерактив порталына җибәрелә.

226. Төзекләндерү өлкәсендәге иҗтимагый контроль мәгълүматның ачыклыгын тәэмин итү һәм төзекләндерү, торак һәм коммуналь хезмәтләр өлкәсендә иҗтимагый контроль турындагы закон нигезләмәләрен һәм башка норматив хокукый актларны исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

## V кисәк. Төзекләндерүнең нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәүгә контроль

227. Гражданнарны, вазыйфаи һәм юридик затларны әлеге Кагыйдәләрне бозган өчен җаваплылыкка тарту Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары нигезендә башкарыла.

228. Гамәлдәге законнар һәм әлеге Кагыйдәләр нигезендә, җаваплылык чаралары куллану Кагыйдәләрне бозган гражданны аның тарафыннан китерелгән матди зыянны каплау бурычыннан азат итми.